№ 20 (1385) 27 май 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

8

Барда районында яшәүче милләттәшләребезнең татарлык рухы, гореф-гадәтләребезгә, тарихыбызга хөрмәте куандыра.

12

Илеш районында туып-үскән Муса Гәрәев – Кызыл Армия тарихында ике Каһарман медален берьюлы алган бердәнбер герой.

14

Балачактан ук кагылып үскән шагыйрә Флера Гыйззәтуллина әдәбият урләрен яулагач та читкә тибәрелә.

Санак саный, уйлый торган чорда, Үзебез дә, әйдә, сынатмыйк!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Кыргызстанның Россиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Гөлнара-Клара Самат Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка «Дуслык» ордены тапшырды.

● Аксубайның Хәсән Туфан музей-йортында Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Клара Булатованың шагыйрь, татар әдәбияты классигы Хәсән Туфанга багышланган китабы тәкъдим ителде.

● Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле Әстерхан өлкәсе Җәмәл, Волгоград өлкәсенең Кече Чапурин авылларында узган Сабан туйларында чыгыш ясады.

● Актаныш районы Усы авыл мәдәният йортында Казан шәһәре филармониясе артистлары катнашында язучы, галим Фарсель Зыятдиновны искә алдылар.

● Лаеш районының Рождествено мәдәният йорты директоры Л.Хәсәнова «Җиңү маршы» халыкара бәйгесендә «Халык вокалы» номинациясендә гран-при яулады.

● Республика сукырлар һәм начар күрүчеләр китапханәсе Санкт-Петербург халыкара китап салоны программасы кысаларында «Бармак очларында татар теле» дип аталган очрашу уздырды.

● Казанның «Мир» кинотеатрында үткән Төрки кино көннәрендә төрки илләрдә төшерелгән фильмнарны 2 меңнән артык кеше караган.

● Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясында «Сүз. Башлангыч код» экспозициясе ачылды.

● Әфганстан татарлары шурасы Кабул шәһәрендә Идел буе Болгарының иң танылган галимнәренең берсе, шушы илдә җирләнгән шәех Болгарины искә алды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә:

"Бездә әдәбиятны пропагандалау начар эшли, ул замана ритмыннан арттарак калган. Хәзерге заман чит ил авторларын, русча язган авторларны карасак, алар дистәләгән телгә тәрҗемә ителә, әсәрләре буенча фильмнар төшерелә, китаплары күргәзмәләрдә катнаша. Автор үзе бит китап пропагандасы белән әллә ни шөгыльләнми дә, реклама, әсәрне җиткерү белән китап агентлыклары, әдәби агентлар шөгыльләнә.

Ә инде нәкъ шул ук югарылыктагы татарча язылган әсәр күп дигәндә китап булып басылып чыга. Ул әле укучысына барып җитмәскә дә мөмкин. Шуннан татар әдәбиятында укырлык әсәр калмады дип сүз чыга».

СЫНАМЫШЛАР

14 майда аяз булса, урак өстендә дә аяз көннәр фаразлана ● 15 майга каршы төндә сандугач сайраса, көн кояшлы булачак; бу көнне бодай һәм арыш чәчәләр ● 18 майда кәбестә үсентеләрен бакчага чыгарып утыртырга була ● 19 майда кыяр һәм борчак чәчәләр; бу көнне чык мул төшсә, кыяр уңа.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 35 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 45 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 10 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **24 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **20 майда 16 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

15 май – гобойчы, педагог, Татарстанның атказанган артисты Мөбәрәк Вазыйх улы Батталовның тууына 110 ел (1912–2006);

– актёр, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Нәҗип Сәмигулла улы Гайнуллинның тууына 110 ел (1912–1969);

– Халыкара гаилә көне.

18 май – төрки телләр белгече, этнограф, профессор Николай Фёдорович Катановның тууына 160 ел (1862–1922).

19 май – Оренбургта «Галимнәр илә залимнәр» әсәре белән «И.Б.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге беренче мөселман драма артистлары труппасы» (булачак «Сәйяр») үз эшен башлый (1907).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 19 май.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(9-16 май)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **30 апрельдән 17 майга кадәр** талак, ашказаны асты бизе һәм ашказаны актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 12 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Тәлгать ӘХМӘДИШИН

Татар гимназиясендә татарча укытсыннар

Инде менә киләсе уку елына 1 нче сыйныфка гариза бирү ташкыны башланды. Кайбер ата-ана, гариза биреп өлгерергә дип, мәктәп ишеген төннән барып саклаган икән. Ә безнең Чаллы шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясендә андый ташкынны ничек аралыйлар?

Сүзне узган ел тәҗрибәсеннән башлыйк әле. Ул чакта 21 татар баласын, урын юк дип, гимназиянең 1 нче сыйныфына кабул итмәделәр. Югыйсә, борып җибәргән балаларны бер сыйныфка туплап, тагын бер сыйныф ачып җибәрергә шартлар бар иде.

Норма буенча гимназия ел саен башта 25 баладан өч беренче сыйныф туплый. Күпмедер вакыт узганнан соң, «норматив» арттырылып, балалар саны һәр сыйныфта 30 га җитә, ә кайберләрендә хәтта артып та китә. Мондый хәл кода-кодагыйлык белән баланы укуга кертүгә юл ача, минемчә.

Мәгълүм булганча, быел гимназиягә татар телендә белем алырга дип 100 дән артык гариза тапшырылган. Димәк, күбрәк сыйныф ачу мөмкинлеге булгач, тотарга да 25 әр укучыдан торган дүрт параллель сыйныф ачарга бит! Татар телендә белем алам дип килгән баланы кире борып җибәрергә нинди явызлык кирәк ул, ә?!

Тәҗрибә бар: 2015/2016 уку елында гимназиядә хәтта биш 1 нче сыйныф ачылды. Укытучысы да, укытырга бүлмәсе дә табылды. Гомумән, ел саен диярлек кабатланып килгән әлеге проблеманы инде әллә кайчан хәл итәргә кирәк иде.

Узган ел, укытучыларның август конференциясе алдыннан, татар телендә белем бирергә бурычлы М.Вахитов исемендәге 2 нче татар гимназиясендә русча дәреслекләр, эш дәфтәрләре кулланулары, укытуның күпчелек сыйныфларда русча яки русча-татарча булуы турында мәкалә язган идем. Шуннан соң, күтәргән мәсьәләләрне хуплап, гимназия ата-аналарыннан рәхмәтле кайтавазлар килде.

Сүзем дә җилгә очмады, агымдагы уку елында гимназиядә кайбер уңай үзгәрешләр күренде. Мәсәлән, «Әйләнә-тирә дөнья» фәне дәреслеге татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, тарихын чагылдырмый, дип мәкаләмдә язган идем, – 4 нче сыйныфлар 2019 елда чыккан яңа дәреслек белән белем ала башлады. Анда аз булса да Татарстанга, татарның күренекле шәхесләренә багышланган урыннар бар.

Алдагы елларда башлангыч сыйныф укучыларына һәр фәннән русча һәм татарча ике дәреслек бирделәр. Нәтиҗәсе шул булды: уку елы барышында дәреслекнең татар телендәгесен күп кенә сыйныфларда кулланмадылар. Бу уку елында исә, мәсәлән, башлангыч сыйныфларда, бары тик татар телендәгесен генә тараттылар.

Берара укучыларның электрон көндәлекләренә өй эшләрен күпчелек очракта русча гына язып бирә башлаганнар иде, хәтта татар теле һәм әдәбият дәресләреннән дә. Бу уку елы башыннан аерым сыйныфларда башлыча ике телдә: татарча һәм русча бирәләр.

Татарстан мәктәпләрендә татарча укытырга тиешле шартлар булмау (татар телендә методик ярдәмлекләр, мәсьәлә җыентыклары, электрон әсбаплар, эш дәфтәрләре һ.б.), ана телендә белем бирүгә шактый зыян сала. Шуңа карамастан, агымдагы уку елында гимназиянең 4нче сыйныфларында җан-фәрман килеп татар телендә белем бирергә тырышалар. Моның өчен Чаллы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимовка да рәхмәт әйтергә кирәк. Татарча белем бирсеннәр өчен, ата-аналарның «татар телендә укытыгыз», дип язган гариза гына җитми, җитәкчедән дә катгый боерык булырга тиеш, күрәсең.

Гимназиядә белем алып 4 нче сыйныфка җитсәләр дә, сүз дә юк, әлегә байтак укучыларның тел байлыгы ярлы. Моның өчен төрле өстәмә ысуллар кулланмыйча булмый. Мисалга, гимназиядә 4 нче «Б» сыйныфын җитәкләгән Гүзәлия Абдуллинаның алымнары игътибарга лаек. Узган уку елында ул татар әдәбияты дәресләренә «Көмеш кыңгырау» газетасыннан берәр мәкалә, яки, уку программасыннан тыш, берәр әдәби китаптан хикәя укып килергә куша иде. Моның өчен укучыларга махсус «уку дәфтәре» ачтырды. Анда укыган язманың исеме язылырга һәм, моны раслап, ата-ананың кулы да куелырга тиеш иде.

Татарча белем-тәрбия белем учагы дип йөртелгән гимназиядә сыйныф җитәкчеләре өчен укучыларда милли үзаң тәрбияләү вөҗдан кушуы югарылыгына күтәрелергә тиеш, әлбәттә. Кайбер укытучылар, моны аңлап, фидакярләрчә төрле чара күрә. Мәсәлән, 4 «В» сыйныфында 1 сентябрь көнне узган сыйныф сәгате "Туган тел" җыры белән башланып киткән. Сыйныф җитәкчесе Илфирә Гыйниятуллина үзе гармун уйнап, укучыларны бастырып җырлаткан. Аннары ул татар телен дәрәҗәләп, аның дөньяда иң камил 14 тел арасына керүе турында сөйләгән.

Гимназиядә 4 нче сыйныфтан башлап фәннәрне төрле укытучылар укыта. Ел барышында әлегә 4 нче «В» сыйныфында математикадан белем бирүче укытучы Сания Закирова: «Контроль эшләрне русча биримме, татарчамы?» – дип укучылардан сорагач, күбесе «татарча!», дип кычкырган булган. Димәк, 4 ел белем бирү барышында сыйныф җитәкчесе Илфирә Гыйниятуллина укучылар күңеленә үтеп, милли оеткы сала алган. Тик мондый күренеш гимназиянең башка сыйныфларында да шулай дип әйтә алмыйбыз. Укучыларның күпчелеге русча белем алуга, китапханәдән русча гына китап алып укуга өстенлек бирә. Гимназиядә авыз тутырып үзара татарча аралашкан укучылар күренми. Болар һәммәсе укучыларда милли аңның түбән булуын күрсәтә.

Гомумиләп әйтсәк, республика мәктәпләрендә даими һәм максатчан рәвештә милли аң үстерүгә игътибар бирүче укытучылар юк дәрәҗәсендә. Алар сыйныфта «татар», «татарлык» сүзләрен кулланып сөйләргә дә куркадыр. Татар мәктәпләрен тәмамлап чыгучылар арасында милли карашлы яшьләр күптәннән күренми.

Узган уку елында гимназиянең 6 «В» сыйныфында татар телендә белем бирү ярыйсы гына куелган иде. Яңа уку елында да шулай дәвам итәр дигән өмет булды, ләкин күрәбез: ярым-йорты, ягъни күпчелек фәннәрдән русча, русча-татарча белем бирүгә күчтеләр. Укучыларга ел башында кайбер фәннәрдән берьюлы русча һәм татарча ике дәреслек китереп тоттырдылар. Мәсәлән, физикадан. Аның татарчасы күз буяу өчен генә бирелгән булып чыкты. Хәзер бу фәнне русча дәреслек белән рус телендә укыталар.

Информатика фәненнән дә ике телдәге дәреслекләр бирелде. Биология фәненнән бары тик татарча дәреслек, әмма, әйтүләренчә, монда да укыту русча. Җәмгыять белеменнән русча-татарча һ.б.

Гимназиянең кайбер укытучылары русча белем бирүне аклап, «туган телдә укытырга терминнар җитми», дип тә хәйлә таба. Бу уңайдан милли хәрәкәт ветераны Габдулла Сәрвәретдиновның бер мәкаләсендә язганнары хәтергә килә: «У многомиллионного татарского народа нет даже права на образование и воспитание детей на родном языке. У нас как-будто бы нет даже желания и сил бороться за свои права. Генофонд нации истощен. Нас убедили, а мы поверили, что на татарском языке нельзя получить полноценного образования. А как же эстонцы, латыши, другие малочисленные народы? Они имеют свои университеты, учатся на родном языке, сохраняют свою культуру...»

Дөрес, 7 «В» сыйныфында аерым фәннәрне татар телендә укыту яхшы куелган. Мәсәлән, алгебра белән геометриядән (укытучы С.Ө.Шәйхаттарова), музыкадан (Л.З.Шәйгәрдәнова). География фәнен дә татарча укытырга тырышалар (З.М.Заһитова). Тарихтан нигездә туган телдә белем бирелә (Р.Г.Каюмов).

Узган ел ахырында М. Вахитов исемендәге 2 нче татар гимназиясенә яңа директор булып Лиза Нәбиуллина билгеләнде. Ул гимназиянең укыту-тәрбия эшендә булган уңышлы башлангычларын дәвам итеп, бихисап кимчелекләрне хәл итәргә алынуын көтәбез.

ЯҢА ТӘРТИП ТӨСМЕРЛӘРЕ

Соңгы вакытларда сәяси даирәләрдә «яңа дөньяви тәртип» дигән гыйбарәне еш ишетергә туры килә. Бу, күрәсең, аны урнаштыру процессының хәлиткеч этапка кгүчүе белән дә аңлатыла. Ә нәрсә соң ул «яңа дөньяви тәртип»? Бу хакта тәгаен генә бер җирдә дә әйтелми. Әлегә ул дөнья тотучыларның уй-ниятләрендә яшерен план вә татлы хыял булып кына яши кебек һәм глобаль сәясәттә бүген бара торган фаҗигале процессларын, билгеле бер вакыттан соң (бүгенге глобаль кризис аша хокукый, рухи, хәрби, психологик, икътисади, социаль һ.б. өлкәләрне дә колачлап үткәрелә торган «комплексы терапия» иҗтимагый аңны дөньякүләм дәрәҗәдә шул «хыял-планнар»га яраклаштырып үзгәрткәч), яшәү тәртибен дә шуларга яраклы итеп үзгәртергә тиеш була. Шуның белән бергә, үзен геосәясәт субъекты дип санаган һәр дәүләт яки берлектә бүген аны үзенчә күзаллау да бар (әйтик, «Зур Европа» проектын гамәлгә ашыру планы, Кытай гегемонлыгына ирешү һ.б. Элегрәк хәтта «Бөек Фин-Угория» проектын гамәлгә ашыру турында да сүзләр йөрде). «Цивилизацияләр бәрелеше» дигәннәрне әнә шул амбициоз планнарның үзара кисешүен, ягъни көчле цивилизацияләрнең кояш астында урын өчен көрәшен аңлата да инде. Ә яңа дөньяви тәртип шуның уртак нәтиҗәсе буларак урнашырга тиеш була.



Бу язмада шундый проектлардан «Глобаль Британия» концепциясенә тукталырбыз. Ул Бөекбританиянең Европа Берлегеннән (ЕС) чыгарга җыенуы (Brexit) алдыннан пәйда булды. Халыкара мөнәсәбәтләр комитеты (Лордлар палатасы) соравына җавап буларак әзерләнгән ул документ «Brexit»тан соң зур сәясәттә булачак үзгәреш шартларында да Берләштерелгән Корольлекнең, дөньякүләм дәрәҗәдә уңышлы уенчы булып калу гына түгел, ә ЕС белән яңа, тирәнтен һәм ныклы партнерлык мөнәсәбәтләре урнаштыруны да күздә тота. Моңа Лондон үзенең халыкара дәрәҗәдәге абруе вә йогынтысына таянып һәм «Brexit»тан соң ачылачак киң мөмкинлекләрне дә исәпкә алып ирешүне максат итте. Аның тышкы сәясәтендә төп таяныч һәм өстенлекле юнәлеш булып АКШ белән берлектә эш итү күздә тотылды. Әмма күчеш чорының башында ук ул җитди генә кыенлыкларга да юлыкты: халыкара мөнәсәбәтләр системасында Лондон илнең урынын яңадан билгеләү һәм тышкы сәясәттә дә өстенлекле юнәлешләрне үзгәртү зарурлыгы белән очрашты.

Үзгәрешләргә ишарә исә Берләштерелгән король институты 2020 елда әзерләгән докладның темасыннан ук күренә: «Контрольгә алырга: Берләштерелгән Корольлекнең тышкы һәм иминлек сәясәтләрендә дәүләт мәнфәгатьләренең яңадан ачылган роле». Анда Бөекбританиянең, соңгы 4 гасырдагы кебек үк, «Brexit»тан соң да глобаль уенчы булып калачагы һәм үз мәнфәгатьләрендә эш итәчәге турында әйтелә. Тышкы һәм иминлек сәясәтләрендә аның төп партнерлары булып Европа-Атлантика берлеге дәүләтләре кала. Шул ук вакытта аңа ЕС яки АКШ артыннан ияру сәясәтеннән туктарга кирәклеге турында да әйтелә. Чөнки аларның Кытай, Иран, Сүрия, шулай ук Бөтендөнья сәүдә оешмасы һәм климатның үзгәрүенә карашы Лондонныкына туры килми икән. Докладта аңа дөньякүләм дәрәҗәдә хезмәттәшлекне тәэмин иткән һәм анда катнашкан илләр үтәргә тиеш булган кагыйдәләр системасыннан баш тартырга тәкъдим ителә, җитди халыкара проблемаларны хәл иткәндә, эре дәүләтләр коалициясенә таянуның күпкә мөһимрәк икәнлеге искәртелә.

Бу яктан, «Глобаль Британия» үзенең тышкы сәясәтендә Британия милләтләр берлегендәге (ә ул 1949 елда Лондон декларациясе имзалангач формалаша, бүген анда 54 дәүләт керә, аларның күпчелеге - Британия империясенең элеккеге колонияләре) партнерларына таянып эш итәргә тиеш була. «Brexit»тан соң аның төп үсеш юнәлеше әлеге Берлеккә кергән дәүләтләр белән сәүдә мөнәсәбәтләрен ныгытуга кайтып кала. АКШның Әфганстаннан китүе һәм AUKUS килешүе төзелүе стратегик яктан инде бу илнең Европадан китүен дә аңлата һәм «Глобаль Британия»гә геосәясәттә үз позицияләрен ныгыту мөмкинлеге бирә. Гади телгә күчереп әйтсәк, дөнья тотучылар инде глобаль сәясәттә идарәнең океан артыннан «иске дөнья»ның англосакс вариантына кабаттан кайтуына ирешә. Ә тышкы һәм хәрби сәясәтнең яңа стратегиясендә, Бөекбритания иминлегенә Европада төп янау Россиядән дип әйтелсә, Кытай инде анда системалы янау чыганагы итеп тә күрсәтелә.

Фоат УРАЗАЙ.

Азан остасын барладылар

Кол Шәриф мәчетендә «Тәртип» радиосы, «Рухи моң» иҗат берләшмәсе һәм Татарстан Диния нәзарәте белән берлектә оештырылган «Татар азаны-2022» III Бөтентатар бәйгесенең йомгаклау чарасы узды.

Конкурс барышында оештыру комитеты йөзгә якын видео кабул итә. Узган еллардан аермалы буларак быел бәйгедә катнашырга теләүчеләр азан әйткән видеоларын җибәргәнче, иң элек азанны дөрес әйтү буенча тест узарга һәм «Татар азаны мәктәбе» тарафыннан оештырылган он-лайн дәресләрне үзләштерергә тиеш булган. Барлык биремнәрне дә дөрес үтәгән катнашучылар арасыннан нәтиҗәдә 10 финалист сайланып алынган.

Татарстанның халык артисты, профессор Миңгол Галиев, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар Хәсәнов, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан урта мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Бөтендөнья татар конгрессының Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф Хәсәнов һәм Ульяновск өлкәсе мөселманнарының үзәк диния нәзарәте вәкиле Рәсүл хәзрәт Фәтхуллов барлык азаннарны тыңлап, үзара киңәшләшкәннән соң, быелгы бәйгенең җиңүчеләрен игълан итте.

«Татар мөәзине» исеменә быелгы бәйгедә Динар Шәймәрданов лаек булды. Икенче урында – Илфат Гыйбадуллин һәм өченче урын иясе – Рузил Ихсанов. Аларның өчесенә дә «Тәртип» радиосында азан әйтү хокукы бирелде. Мәчетләрдән яңгырый торган азанның сыйфатын үстерү, сәләтле азан әйтүчеләрне барлау, мәхәллә тормышын җанландыруны максат итеп куйган «Татар азаны» проекты киләсе елда да үз эшен дәвам итәчәк.

Коръән укуда ярыштылар

Ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан халыкара Изге Коръән уку конкурсы узды. Ул Казанда Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең Яшьләр башкаласы буларак уздырылган беренче чара булды. Бәйгедә җиңүчеләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бүләкләде.

Конкурс онлайн һәм офлайн форматта үтте. Жюри Коръәннең дөрес укылышын һәм Коръән сүрәләренең хәтердә калу сыйфатын бәяләде. Җиңүчеләр 10 мең доллар күләмендә акчалата премия алды. Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында иң яхшы өч укучы билгеләнде.

Ир-атлар арасында конкурста Муса Гайтиев (Чечня Республикасы) җиңүче булды. Икенче урынны Мисырдан Мәхмүт Халәд Мәхмүд Суәйд яулады, ә өченче урынга Катар вәкиле Хамад Абдулла Т.А.Алҗумайлы лаек булды. Хатын-кызлар арасында беренче урынны индонезияле Деви Юкха Нидха алды. Икенче урында - Палестинадан Исраа Мөхәммәд Әсам Сәлах, өченчедә – Бөекбританиядән Хәлимә Абдинасир Әхмәд.

1 нче биттә – видеоуенда җиңгән балалар шатлыгы. Фото: pxhere.com

Тәүге рәсми дин

Ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулу бәйрәменең төп тантанасы Болгар музей-тыюлыгында булды. Анда Ислам хезмәттәшлеге оешмасы каршында Россиянең махсус вәкиле Р.Абдулатипов, Россия Президенты хакимиятенең Эчке сәясәт идарәсе башлыгы А.Вылегжанин, Россия Мәдәният министры урынбасары, Федераль оештыру комитетының җаваплы сәркатибе О.Ярилова, Татарстан Президенты Р.Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиев, Татарстан Премьер-министры А.Песошин, Татарстан вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе В.Шәйхразиев һәм Россия мөфтиләре, төбәкләрнең дини оешма җитәкчеләре кебек дәрәҗәле кунаклар булды. Алар арасында баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Төньяк Кавказ мөселманнарының Координацион үзәге рәисе Исмаил хаҗи Бердыев, Россия мөселманнары Дини җыены башлыгы Әлбир хәзрәт Крганов, шулай ук Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл һ.б. бар иде. Моннан тыш, әлеге чарага 76 чит мәмләкәттән килгән делегацияләр дә кушылды. Гомумән алганда, Болгардагы төп бәйрәм чарасына 20 меңнән артык кеше катнашты.

Тантана Истәлек билгесе алдындагы мәйданда Идел буе Болгар дәүләтенә ислам дине килүне һәм Әхмәд ибне Фадлан юлын чагылдырган театральләштерелгән тамаша белән ачылып китте.

Бәйрәмне тантаналы рәвештә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләү чыгышы белән башлап җибәрде. Ул, беренчеләрдән булып, Болгарның изге җирендә мөселманнар җыеннарын үткәрү идеясен үстерә башлаган Россиянең Баш мөфтие Тәлгать Таҗетдингә һәм шулай ук исламның изге урыннарын торгызу буенча зур эшләре өчен Минтимер Шәймиевкә, һәм «Яңарыш» фондына рәхмәтләрен белдерде. «Болар барысы да Татарстан, Россия мөселманнарына, кунакларга 1100 ел элек ата-бабаларыбызның ислам динен рәсми кабул итүен зурлап билгеләп үтәргә мөмкинлек бирде. Һәрберегезгә рәхмәт белдерәсем килә», – диде ул.

Аннары Россия Президенты Владимир Путин, Россия Премьер-министры Михаил Мишустин һәм Төркия Президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган исеменнән бәйрәм уңаеннан котлау телеграммалары укылды.

М.Шәймиев 2014 елда Болгар тарих-археология комплексының ЮНЕСКО Бөтен дөнья мирасы исемлегенә кертелүен искә алды. Бу инде бөтен дөнья белгечләре тарафыннан Болгарның иң төньяк биләмәләрдә ислам динен ирекле кабул итү урыны буларак танылуын да белдерә. «Бу – уртак уңышыбыз, эшебезнең лаеклы нәтиҗәсе. Борынгы Болгар шәһәрен торгызу безнең тарихи мирасыбызны саклаган халык булуыбызны күрсәтте», – диде ул.

Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин Болгарны, татар халкын таныту буенча алып барган эшчәнлек турында сөйләп узды, Изге Болгар җыенын үткәрү тарихын бәян кылды, аның, 1989 елда һиҗри тәкъвим буенча ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы итеп, ай дәвамында меңнәрчә кеше катнашында үткәрелүен искә төшерде.

Камил хәзрәт Сәмигуллин, христианлыкның Россиягә рәсми рәвештә 988 елда гына керүен әйтеп, ислам диненең, 922 елда ук рәсми төстә кабул ителгәч, Россия җирлегенә беренче дин булып керүен искәртте. «Шуның өчен бу көн барыбыз өчен дә әһәмиятле», – диде ул. Олы кунаклар халык белән бергә баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдингә ияреп намаз укыды.

1100 еллыкны бәйрәм итү чарасы көрәш буенча Дөнья кубогына ярышлар, концерт программасы белән дәвам итте – җыелган халык алдында «Илаһи моң» рухи мирас әсәрләрен башкаручыларның төбәкара конкурсы лауреатлары һәм республиканың әйдәп баручы иҗат коллективлары, рухи музыка башкаручы осталар чыгыш ясады. Моннан тыш, Болгар ислам академиясендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан истәлекле почта маркасына тантаналы рәвештә мөһер куйдылар. «Беренче көн» конвертында рәссам К.Тиллиның «Борынгы Болгар. Кече манара. 1868 ел.» дип язылган литографиясе чагылдырылган.

Сөембикә КАШАПОВА.

Төньяк башкалада татар җырын яңгыратты ул

Санкт-Петербургның К.С.Станиславский исемендәге Актерлар йорты концерт залында күренекле мәдәният эшлеклесе, педагог, Н.А.Римский-Корсаков исемендәге Санкт-Петербург консерваториясе профессоры, Россия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Сәйрә Вельшакованың тууына 100 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе узды. Аны Татарстанның Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллеге һәм өлкәнең татар җәмгыяте әзерләгән иде.

Сәйрә Вельшакова гомере буе консерваториядә эшли. Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң, ул Казанда Рәшит Ваһапов белән эшли, аннары Ленинградка күчеп китә. Башта Җәмәгать китапханәсендә хезмәт куя, озакламый аны Ленинград консерваториясенә эшкә чакыралар. Төньяк башкалада яшәп, ул башта – Ленинград, аннары Петербург татар җәмгыятендә агарту эшчәнлеге алып баруга зур игътибар бирә. Шәһәрнең иң яхшы залларында татар җәмгыяте әгъзалары өчен күпсанлы концертлар куя.

Сәйрә Вельшакова әлеге концертларда татар телендә җырлар һәм романслар башкара, аның чыгышлары беркемне дә битараф калдырмый, һәрвакыт көчле алкышларга күмелә. Әлеге чараларда булган кешеләр бүген аның музыкаль мәдәниятне үстерүгә керткән өлешен рәхмәт хисләре белән искә ала. 2006 елның 15 февралендә Капелла залында Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган соңгы концертын биргәннән соң, Сәйрә Вельшакова шул ук елның 7 апрелендә вафат була.

Ильяс Камалның затлы кичәсе

С.Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында композитор, Муса Җәлил бүләге иясе Ильяс Камалның авторлык концерты үтте. Затлы кичә Казан дәүләт консерваториясенең «Татарика» оркестры башкаруында (җитәкчесе – Ринат Халитов) «Кыпчак рапсодиясе» белән башланды. Әлеге оркестр кичә буена композиторның оркестр өчен язган әсәрләрен, җырларын, романсларын, халык көйләренә эшкәртмәләрен, «Минем Такташ» операсыннан өзекләрне яңгыратты. Ильяс – күпкырлы талант иясе. Ул виртуоз виолончель остасы да, дирижер да әле. Өстәвенә, халык көйләрен гаҗәеп сизгерлек белән эшкәртеп, оркестрга салучы да ул. Кичәдә Ильяс тагын сокландырды – кайчандыр төрки бабаларыбыз яратып уйнаган, соңрак ислам дине таралу белән бәйле рәвештә онытылган борынгы уен коралы – кылкубызда уйнады. Әлеге уен коралының авазын сүз белән тасвирлау мөмкин түгел, ул күңел төпкелендә йоклап яткан тарихи хәтерне уятырга сәләтле, аның моңында даладагы ирекле җил авазы да, сабый елаган аваз да, очып барган уклар сызгыруы да бар сыман… Ильяс бу уен коралын халкыбызга кире кайтару, аны таныту юлында зур эш башкара: кылкубыз өчен әсәрләр, эшкәртмәләр яза, концертларда чыгыш ясый.

Концертта шулай ук композиторның Уфадан килгән музыкант дуслары чыгыш ясап, кичәне курай, кубыз моңнары белән баетып җибәрде. Ильясның җырларын танылган җырчылар Филүс Каһиров, Артур Исламов, Эльза Заяри, Илгиз Мөхетдинов башкарды. Сүз уңаеннан, Эльзаның әлегә кадәр мактаулы исеме булмау һич тә аңлашылмый. Искиткеч белемгә ия, Казан консерваториясеннән соң Петербургта Мария театры академиясен тәмамлап кайткан, бик җитди халыкара вокал конкурсларында җиңүләр яулаган, гүзәл сопранолы, күз явын алырлык төс-кыяфәтле шушы асыл кызыбызның кадерен белмәүме, күрмәгәнгә салышумы бу? Күпләр мактаулы исемнәрне сәхнәдә шырдый-бырдый такмак җырлап, нота да танымаган килеш алып, лаек булмаган килеш күтәреп йөри, ә дөньяның кайсы сәхнәсендә җырласа да сынатмаслык Эльзаны нигә «күрмиләр»?

Ильяс Камалның авторлык концерты күңелләрне баетып, рухландырып, уйландырып, бер тында узып китте. Чын милли, яхшы музыкага сусап килгән тамашачыга ул зур бүләк булды.

Эльмира СИРАҖИ.

- Дөньяда иң тәбәнәк буйлы милләт – японнар, иң озын буйлысы – голландиялеләр.
- Угандада халыкның 50 процентын 15 яше тулмаган бала-чага тәшкил итә.
- Планетада һәр өч секунд саен бер бәби туа.
- Кеше үз гомеренең 5 елын ашауга сарыф итә.
- Планетабызда һәрвакыт йөз кешедән берсе исерек була.
- Дөньяда һәр бишенче кеше психик тайпылышлардан интегә.
- «Титаник» корабын төзү 7 миллион долларга, аның турында фильм төшерү 200 миллион долларга төшкән.
- Дөньяда макарон эшләнмәләренең 350 дән артык төре мәгълүм.

Шушы көннәрдә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулды. 922 елда булган бу олы тарихи вакыйгага әзерлек берничә ел элек башланды. Ул федераль дәрәҗәдә дөньяның мөселман дәүләтләреннән, Россиянең төрле почмакларыннан килгән вәкилләр, илчеләр, мөхтәрәм кунаклар, югары җитәкчеләр катнашында зур тантаналар белән билгеләп үтелде.

Милли тормыш һәм дин

«Kazan Expo» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев катнашында «Милли тормыш һәм дин» Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының рәсми ачылышы узды. Чарага 5 чит илдән һәм Россиянең төбәкләреннән 1100 делегат чакырылган иде. «Форум тәҗрибә уртаклашу, актуаль мәсьәләләр хакында фикер алышу урыны булыр, безне тагын да берләштерер», – дип билгеләп үтте Шура рәисе үзенең чыгышында. Дин әһелләре соңыннан биредәге оештырылган «Russia Halal Expo 2022» күргәзмәсе белән дә танышты.

Истәлекле көн хөрмәтенә бәйрәм чаралары элекке «Кырлай» паркы биләмәсендә 10 мең кеше сыйдырачак яңа Җәмигъ мәчете төзелеше башланачак урынга беренче ташны кую белән дәвам итте. Россия хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин РФ Президенты Владимир Путинның да Россия мөселманнарының ата-бабалары традицияләренә һәрвакыт хөрмәт белән караvы турында берничә тапкыр әйткәнен искәртте. Татарстан Президенты Р.Миңнеханов үз чыгышында 1767 елда татарлар Әби-патша дип атаган Екатерина икенченең Казанда таш мәчет төзелешенә рөхсәт бирүен искә төшерде. Хәзер бу борынгы мәчет Ш.Мәрҗани исемен йөртә. Ә инде 1990 елларда Татарстанның беренче Президенты М.Шәймиев тәкъдиме белән Кремль биләмәсендә Кол Шәриф мәчете төзелеше башланып китүе шулай ук тарихи әһәмиятле вакыйгага була. Хәзер ул халкыбызның иң яраткан, күренекле Аллаһ йортларының берсе.

Хәзерге вакытта Җәмигъ мәчете проектына халыкара конкурс бара. Мәчет архитектурасы халкыбызның күп гасырлык милли мәдәнияттен чагылдырырга тиеш, дип уйланыла. «Халкыбызның дине тагын да ныгысын Аллаһыга тапшырып, эшне башлап җибәрәбез», - дип белдерде Татарстан

Президенты. Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин да Казанның Җәмигъ мәчетен төзү хак юлда яшәвебезне күрсәтүен искәртте. Тантаналы чара Россия хөкүмәте рәисе урынбасары М.Хөснуллин, ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиев, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин һәм башкалар катнашында узды. Бу көнне Казанның Җәмигъ мәчете төзеләчәк урында беренче җомга намазы Камил хәзрәт Сәмигуллин имамлыгында укылды.

Казанның М.Җәлил театры бинасында Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан «Милли тормыш һәм дин» Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы булып үтте. Милли шура рәисе В.Шәйхразиев бүген ислам дининең Россиядәге көндәлек тормышны иминлек юлыннан алып баручы ышанычлы нигез булуын искәртеп, Россия Президенты В.Путин карары нигезендә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүне зурлап билгеләп үтүнең моны ачык дәлилләвен әйтте. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин олуг бәйрәмнең әһәмиятен һәм тирән мәгънәсен билгеләп үтте. Ул мөселманнарның Россиядә борынгыдан яшәүче халык икәнлеген дә күрсәтә, шул ук вакытта аларның Россия дәүләтчелеген саклауда төп көчләрнең берсе булуын да раслый. Ил хакимияте дә мөселманнарның Россиянең икътисадын үстерүдә, милли мәнфәгатьләрен яклауда, җәмгыятебездә татулыкны ныгытуда зур өлеш кертелүен таный. Бәйрәм чаралары Россиянең барлык төбәкләрендә дә, чит илләрдә дә илебез – күп диннәр һәм халыклар өчен уртак Ватан булуын аңларга, Россиянең ислам дөньясының зур бер өлеше икәнен күрергә ярдәм итәр. Әлбәттә, татарлар өчен бу юбилей аеруча зур әһәмияткә ия. Идел буе Болгарстаны сәяси картадан юкка чыкса да, Татарстан бүген Россиянең иң уңышлы төбәкләрнең берсе булып тора. Илебездә аны ислам үзәге һәм мөселманнар өчен иң уңайлы төбәк буларак белүәр. Республикабызда динебез үсеше өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Татарлар ислам динен күтәрүгә хезмәт итә һәм, Россия үзәгеннән торып, динебезнең асыл кыйммәтләрен тарата.

Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти, шәех Равил хәзрәт Гайнетдин Касыйм шәһәрендә Хан мәчете каршындагы мәйданда Сөембикә ханбикәгә һәйкәл ачылачагын, Касыйм шәһәрендәге Хан мәчетен реставрацияләү, ханнар җирләнгән ике такыянең (мавзолей) яңартылу эшләрен башлап җибәрәчәкләрен хәбәр итте. Шулай ук, Мәскәүдә сакланып калган тарихи мәчетләрнең иң борынгысы булган тарихи татар мәчете һәм мәдрәсә бинасын төзекләндерү башланачак. Бу хакта Мәскәү шәһәре мэры С.Собянин белән килешенгән, тарихи мәчетнең 200 еллык юбилеен уздыруга Россия Президенты В.Путин да ризалык биргән.

Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе шулай ук, Түбән Новгородта «Ярминкә» мәчете булганын, ул Шәрык мәчете буларак, анда Төркия һәм фарсы матди ярдәмнәре дә кертелгәнен искәртте. Ислам кабул итүнең 1100 еллыгында шул мәчетне яңадан торгызу максатыннан нигез ташы куелачак. Шулай ук юбилей елында «Россия Федерациясендә ислам» энциклопедик сүзлеген бастыру да күз алдында тотыла. Анда Муса Бигиев, Ризаэддин Фәхретдин, Хөсәен Фәезханов һ.б. мирасы серияләрендә галимнәрнең әсәрләрен татарча һәм рус телендә нәшер итү ниятләнә. Энциклопедик сүзлек көзен укучылар кулына тапшырылыр, дип уйланыла. 2022 ел ахырында Мәскәүдә халыкара мөселманнар форумы да узар дип көтелә.

Россия мөселманнары дини җыены рәисе Әлбир хәзрәт Крганов татар дин әһелләре форумының елдан-ел камилләшә баруын әйтеп, үзара аралашу өчен уникаль мәйданчык булдырылуын Татарстан Президенты Р.Миңнехановның казанышы дип атады. Шул ук вакытта быел ел дәвамында төбәкләрдә зур, күңелле чаралар тынып тормаячак. Волгоград, Нижневартовскида, Чуашиянең Урмай авылында яңа мәчетләр, Мәскәүдә мәдрәсә ачу планлаштырыла. Екатеринбург, Иркутск, Новокузнецк, Сургутта, Чабаксарда, Ленинград өлкәсенең Тосна районында яңа мәчетләр калкып чыгарга тиеш. Алар төзеләчәк урынга нигез ташлары салуны тантаналы төстә уздырылыр, дип көтелә. Кемерово шәһәрендә болгар бабаларыбызга һәйкәл ачу да мөселманнар өчен зур бәйрәмгә әверелер. Россиянең Баш мөфтие Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин Изге Болгар җыенын үткәрү тарихын бәян кылды һәм табигатьнең дә Болгар җыены үткәрелгән чакта рәхимле булуын әйтте.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Коръәннең мөселман дөньясында фәнни-дини җәмәгатьчелек тарафыннан танылган «Казан басмасы» турында да сөйләде. Аңа кадәр Коръән Европада һәм Петербургта басылып чыккан, әмма алар, Изге Китабыбызның оригинал текстыннан тайпылышлар булу сәбәпле, фәнни кыйммәткә ирешми. Ислам илләрендә Коръән, «Казан басмасы» дөнья күреп, 100 ел үткәч кенә күпләп басыла башлый. «Казан басма»сы үзенчәлекле шрифтка ия булганга күрә дә дөньякүләм танылу ала. Безнең чорда ул төрле елларда күп тапкырлар репринт сыйфатында басыла. Ислам динен кабул итүнең 1100 елында нәзарәт белгечләре «Казан басма»сының тарихи типографик оттискысыннан шундый ук компьютер шрифтларын ясаган, аннары Коръән текстын «Казан басма»сында яңадан җыйган. Бу эш революциягә кадәрге күренекле татар галимнәре Ш.Мәрҗани һәм М.Бигиев искәрмәләрен исәпкә алып, заманча халыкара стандартларга туры китереп алып барылган. Яңартылган «Казан басмасы» шушы рәвешле инкыйлабка кадәрге оригинал шрифтларның чын тарихи йөзен саклап калып бастырылган. К.Сәмигуллин Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яңартылган «Казан басма»сының электрон нөсхәсен һәм компьютер шрифтын өммәтнең гомум кулланышына тапшыруын хәбәр итте. Аларны түләүсез рәвештә йөкләп алырга мөмкин.

Президент Р.Миңнеханов ата-бабаларыбызның 1100 ел элек ислам динен рәсми кабул итүен билгеләп үтү татарлар һәм республика өчен генә түгел, Россиянең барлык мөселманнары өчен әһәмияткә ия бәйрәм булуын ассызыклап үтте. Ул Идел буе Болгарында ислам кабул итүнең 1100 еллыгы зурлап үткәрелүе өчен Россия Президенты В.Путинга һәм бәйрәм тантаналарын оештыру һәм уздыру комитеты рәисе Марат Хөснуллинга рәхмәтләрен белдерде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Шигырь җанлы җир улы

Танылган җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь, күп кенә популяр җырлар авторы Рөстәм Зәкуан белән бергә төшкән фотосурәт аның турында якты истәлекләремне яңартып җибәрде. Әле бит ул әнисе ягыннан безнең якын туганыбыз да: Римзә апа гомере буе китапханәче, әтисе Газизҗан абый янгын сүндерүче булып эшләде. Бигрәк тә Газизҗан абый киң күңелле кеше иде, Азнакайга килгән саен редакциягә – эш урыныма сугылып чыга, кайчагында гаиләбездә гөрләшеп утырып, иртән генә кайтып китә иде.

●Журналист Наил Абдуллин (сулдан), шагыйрь Рөстәм Зәкуан, Әсгать Сәгытдинов. 1980 ел.

Рөстәм мәктәптә укыганда, үсмер егет булып килгәндә, әдәби иҗатка тартылуын белдереп, инша-язмалары белән яныма гел килеп йөри – шул әйберләрен газетабыз битендә күрсә, кош тоткандай була. Бу чакта әле аның шагыйрьлек сыйфатлары да сизелми, ул комбайнчы, тракторчы, терлекче абый-апалары турында җылы сурәтләмәләр яза, аларда авылдашларының эш-шөгыльләре, киләчәккә уй-хыяллары, ягъни каләмгә омтылышы чагыла иде. Шуңадыр да әнисе эшләгән китапханәнең актив укучысы булу һәм яшь иҗатчылар белән аралашу Рөстәмне 1974 елда Тымытык урта мәктәбен тәмамлауга Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга баруына этәргәндер. Ялларга кайтканда редакциябезгә кагылмыйча калмый, ә бераздан инде практикасын да «Маяг»ыбызда үтте; без бергәләп авылларга, оешмаларга йөреп, хезмәт кешеләрен, тормышыбызның күп якларын күреп кайтабыз һәм билгеле ки, газетабыз битләрендә яктыртып чыгабыз. Аның җаваплы сәркатибебез Наил Абдуллин белән электәнге дуслыклары да ачык күренеп тора иде. Кечкенәдән кул арасына кереп, үсә төшкәч, кирәксә көтүен көтеп, басуларда сабан төрәннәрен ялт чистартып, яше керүгә үк шофёр правасы алып машина йөрткән егет хезмәттән ямь таба иде. Ниһаять, университетны тәмамлагач, ул редакциябезгә кайтып әдәби хезмәткәр булып эшли башлады. Инде гаиләле – сөйгән яры Фәния дә университетта үзе белән бергә укыган кыз. Рөстәм көн дә берничә чакрымдагы Үчәллесенә кайтып йөри, аны шәһәрдән фатир алып булыр дип ышандыралар, тик ул юк та юк. Шулчак колхоз рәисе, Югары Совет депутаты Тәлгат Фатыйхов аны үзе янына чакыра. Шулай итеп Рөстәм үзе үскән – буй җиткергән якта биш ел дәвамында партия оешмасы секретаре, колхоз рәисе урынбасары вазифаларын үти, дилбегәне тапшыру вакыты җитеп килгән Тәлгать абыйсы аны үз урынына әзерләргә уйлый. Бу вакыт аралыгында егетне җитәкче кадрлар әзерләү мәктәбенә дә җибәреп кайтаралар. Тик тормыш тәгәрмәче син дигәнчә тәгәрәми, коммунист икәнсең, каршы килә алмыйсың – Рөстәмне элекке җитәкчеләре алып бара алмаган «Янтарь» совхозына директор итеп куялар. «Октябрьнең 40 еллыгы» дигән хуҗалыктан – олы гына Мәсгут авылыннан аерылып чыккан умартачылык булып киңәеп, тирә-юньдә дан тотасы бу «Янтарь», нигәдер гәрәбә кебек балкый алмый интегә, югыйсә эшче көчләре дә бар кебек, әмма бер төенгә ныклап төенләнә алмагач, Крылов мәсәлендәгечә, кирегә тәгәри. Рөстәм Зәкуанов моны үзенчә хәл итә: иң элек совхоз эшчеләренә үзләренә иркен тормыш итәрлек шартлар тудырырга тырыша. Терлекчелектәме, игенчелектәме – эшеңне җиренә җиткереп үтисең икән, сиңа кирәк чаклы мал-туар, кош-корт асрарга азык-төлек ягыннан уңайлы мөмкинлекләр бирелә. Нефть чыгару, төзелеш оешмалары белән – бигрәк тә янәшәдәге «Җәлилнефть» идарәсе белән ныклы элемтә урнаштыра Рөстәм. Тора-бара җитәкчеләр арасында сүз китә – Зәкуанов башкалар кебек министрлыктан, хакимияттән биргәнне генә көтеп ятмый; район башлыгы Әнәс Исхаков та Рөстәмнең бу үрнәген һәрдаим әйтә килә. «Янтарь» совхозы кыска гына вакыт эчендә икътисади күрсәткечләре белән аерылып тора башлый. Килүенең өченче елында инде заманча шартлары тудырылган йортлары белән яңа урамнар калкып чыкты, урам-тыкрыкларга таш-асфальт түшәлде. Билгеле, монда күчеп килүчеләр дә артты, хәтта чират барлыкка килде. Бер килүемдә күрәм: фермадагы биналарга яңабаштан реконструкция үткәрелгән. Эчләрендә стеналары кафель белән тышланган, терлекчеләрнең күпчелек авыр эшләре җиңеләйтелгән, азык кертү-тарату, эшкәртеп-тәмләндереп ашату, чисталыкны тәэмин итү механикалаштырылган. Ял бүлмәләре дә зәвыклы: бәйрәмнәр, туган көннәрне дә онытмыйлар, үзе белән бергә Фәниясе дә күп кенә бәйрәм табыннары өчен сый-рызыкларны әзерләүдә катнаша. Әлбәттә, уңайлы көнкүреш мөмкинлекләре тудыргач, кунак ашы – кара-каршы. Җавап әҗере дә шулай: «Янтарь»ның матур күрсәткечләр яулаучы терлекчеләре, игенче-механизаторлары районның алдынгылар слётларында дәрәҗәле бүләкләргә лаек була. Рөстәм Зәкуанов туган авылында, «Янтарь»да эшләгән чагындагы кебек, монда да биш ел эшләү дәверендә башка җитәкчеләрнекенә караганда җир белән күк арасындагы үзгәрешләр барлыкка китерә. Ул техника паркын, ул ындыр табакларын аласыңмы?! Шуңа да район, республика семинарлары еш кына биредә үткәрелә. Күп җитәкчеләр авылның мәгариф өлкәсенә борылып та карамаган бер вакытта, Рөстәм Газизҗан улы шаккатмалы күренеш барлыкка китерә: авылның күренекле мәйданында табигать күркенә ямь өстәп күп катлы иркен укыту-тәрбия-спорт комплексы калкып чыга. Моны тынгысыз Зәкуанов нефть, төзелеш оешмалары ярдәме белән барлыкка китерә. Бинолар яңа, заманчалыгы ягыннан тирә-юньдә аерылып, менә хәзер ничәмә еллар үткәч тә, аның хезмәтенә һәйкәл булып тора. Тикмәгә генә аңа Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелмәгән икән!

Булдыклы кеше бер урында гына озак тоткарланмый: Р.Зәкуанов «Татнефть» берләшмәсенең эшчеләрне тәэмин итү идарәсе җитәкчелегендә дә озак тормый. Азнакай районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары булып күчә. 2004 елның мартында Татарстан Дәүләт Советы депутаты итеп сайлана, Дәүләт Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе урынбасары итеп билгеләнә. Кайда гына эшләсә дә, ул гади, эчкерсез, ярдәмчел, кешелекле булып кала. Туган авылы Үчәлле һәрдаим аның күңел түрендә яшәде. Депутат булгач, аның зур колач белән мәдәният-спорт комплексын яңартып, районда беренче җәмәгатьчелек үзәге итеп төзүдә ярдәме күпләр өчен үрнәк булды; бу матур күренешкә карап ул үзе дә бик шатлана иде.

Сайлаучыларның наказларын вакытында үтәү, борчыган сорауларына җавап бирү өчен, Рөстәм Газизҗан улы безнең «Маяк» газетасы битләрендә еш кына гади язучы стилендәге язмалары белән чыгыш ясый иде. Әле аның шагыйрьлегә дә күренмәгән вакытлар югыйсә. Чиләгенә күрә капкачы, дигән кебек, Рөстәм туганыбызның җәмәгате Фәния Вәкил кызы да үзе кебек үк үтә игелекле, һәркемгә сүзен әтрафлы әйтә белүче, зирәк гыйлемле педагог – Татарстанның атказанган укытучысы. 1979 елдан бирле мәгариф системасында эшли. Ун ел Илбәк мәктәбен җитәкли, шушында туган Советлар Союзы Герое Әкрам Вәлиев мемориалында хәрби-патриотик тәрбияләү эшен җәелдерә. Аннары Әлмәт төрек лицее директоры урынбасары, берара типография директоры булып та эшләп ала. Казанга күчеп килгәч, Биектау районындагы туган авылы Мүлмәдә дүрт ел мөгаллимлек иткәннән соң идарәче компаниядә генераль директор урынбасары вазифасын башкара. Кызлары Айгөл һәм уллары Айваз югары белем алып, әти-әниләренең эстафетасын лаеклы дәвам итә.

Рөстәм исә барыннан да бигрәк үзен шагыйрь җанлы моң иясе – халкыбыз күңелен яулаган күп санлы җырлар авторы итеп танытты. Әле дә хәтердә: 2007 елда, Рөстәм Зәкуан шагыйрь булыр дип башка да китермәгән бер чакта, редакциядәге бүлмәмә Марсель Галиев белән икесе килеп керде һәм аның «Яшәү мәгънәсе» дигән тәүге китабын бүләк итте. Китапта әдәбиятыбызның данлыклы әһелләре Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев, Рафис Корбан аның иҗатына югары бәя бирә. «Рөстәмнең барлык шигырьләре дә минем күңел аша узды. Чөнки мин аның әлегә кадәр чыккан өч китабының да мөхәррире булдым. Үзенең әдәбиятка шактый соңлап, илле яше тулып китканда гына килүен акларга теләгәндәй, ул рус телендә тәрҗемә китабын да чыгарырга өлгерде», – дип, Р.Корбан дустының озын булмаган гомерендә бай иҗади мирас калдыруын ассызыклый. Ә 2018 елда әле аңа «Таттелеком» гаммәви акционерлык җәмгыяте иҗат төркеме составында бу җәмгыятьнең Матбугат үзәге җитәкчесе буларак, тарихи мирасыбызны саклау, халкыбыз өчен кадерле булган истәлекле урыннарны яңадан торгызу, милләтебез язмышы өчен гомерләрен багышлаган бөек шәхесләребезнең исемнәрен кире кайтару, аларның музейларын булдыру юнәлешендә башкарылган зур колачлы эшләре өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Моннан алда әдәби җыентыклары һәм әдәбияттагы уңышлары өчен ул Һ.Такташ исемендәге әдәби бүләккә лаек булган иде. Хәзерге көндә туган авылы Үчәлле китапханәсендә гомере буе авылдашларына мәгърифәт нуры өләшкән Римзә апага һәм мәдәният йорты әргәсендә улы Рөстәмгә куелган мемориаль такталарда аларның изге рухлары нурланып, якты балкыш биреп тора.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ,
матбугат ветераны.
Азнакай шәһәре.

Рөстәм ЗӘКУАН

Сары яфраклар каплаган Мәңгегә эзебезне...

(Шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Рөстәм Зәкуанның туuына 65 ел)

* * *

Язмыш мине күп сынады,
Алдандым әллә ничә...
Алданыр идем мең кабат,
Яшьлегем тагын килсә.

Язмыш мине күп сынады,
Адаштым әллә ничә...
Адашыр идем назыңда,
Башканы эзләмичә.

Язмыш мине күп сынады,
Сагындым әллә ничә...
Таба алмыйм яшьлегемне,
Калганмы айлы кичтә?

Язмыш мине күп сынады,
Югалдым әллә ничә...
Син булганга сөенеп яшим,
Дәрт-егәрем сүнмичә.

Язмыш мине күп сынады,
Югалттым әллә ничә...
Яшьлектә калган хисләрне
Кузгаттың кабат кичә.

* * *

Төнге күкнең зәңгәр бишегендә
Ай нурлары моңсу тирбәлә.
Ялгыз калган ярым, төшләремдә,
Зинһар өчен, мине тиргәмә.

Иңнәреңә салып көянтәңне,
Кайтып керерсең күк чишмәдән.
Йөрәгемдә нидер өзелдеме? –
Хәбәреңне алгач читләрдән.

Төнге күкне кинәт кисеп үтеп,
Очкын булып, йолдыз атылды.
Сагыш булып, кайнар очкыннары
Күңелемә, ахры, кадалды.

Йокым качты, ерак еллар аша
Син кайтырсың кебек үткәннән.
Ник калдырдың, диеп, ялгызымны,
Дәштең бугай миңа күкләрдән...

* * *

Тәрәзәдән буран булып
Дәшәсең, белмим, кая?
Ак бураннар арасында
Аралар ерагая.

Бураннарда салган эзләр
Югалды, беләм, күптән.
Күзләрең һаман елмаеп
Дәшәләр кебек күктән.

Кар буранын ера-ера
Эзлимен соңгы көзне.
Сары яфраклар каплаган
Мәңгегә эзебезне...

* * *

Күк катына җиткән кебек булам,
Чатыртавым, сиңа менгәндә.
Болыт юрганыңа уралам да
Башым куям яшел мендәргә.

Җегәр иңә гүя тәннәремә,
Алып кебек сизәм үземне.
Офыклардан тамган сихри нурлар
Назларына күмә күземне.

Каеннарың ала кайгыларны,
Кылганнарың йөгерә, тирәләп.
Байбакларың танымады, ахры,
Нидер куйды җанны телгәләп.

Кайтканың юк нигә күптәннән, дип
Дәште гүя синең имәннәр.
Хәер-дога көтеп яши читтә
Туган җирләреннән киткәннәр.

* * *

Ник килгәнмен фани бу дөньяга?
Нинди язмыш фараз углыңа?
Тәкъдиремә ниләр салынган соң?
Ходай нәрсә язган колына?

Җавап эзләп бик күп сорауларга,
Узып барам гомер сукмагын.
Безнең эзләр – еллар тузанында,
Сыртка төште кайчак тукмагы.

Назларында коенып чибәрләрнең,
Һушсыз калдым сылу кызларга.
Өметләндем – яшәү тора гүя
Гөлчәчәкле ямьле язлардан.

Хыянәтне кайчак сизми калдым,
Дус сүзе дип ышанып тыңладым.
Рәнҗеттеләр керсез күңелемне,
Яшереп яшем кайчак еладым.

Бушкуыклар йөри, түш киереп,
Күңел кала шуңа кителеп.
Милләт өчен җанын бирердәйләр
Читтә йөри һаман, тибелеп.

Мең сорауга – миндә бер җаваптыр.
Ялкын җитми безнең җаннарда.
Үз кадерен белгән халык кына
Үз бәхетен яклар җиһанда.
Татар рухын саклар дөньяда...

* * *

Күп сөйлибез нотыкларны,
Милләтне, дип, җыйнарга,
Кул кушырып утырабыз
Югары җыеннарда.

Бил алышып Сабантуйда,
Татарны танытсак та;
Ирек даулап мәйданнарда,
Якага ябышсак та...

Дулап кына ни кырасың,
Бердәм фикер юк供 бездә.
Татарлыкны тою җитми
Иң элек үзебездә.

* * *

Рафис Корбанга

Күңелкәең чиста синең,
Ходай сиңа салган иман!
Үзең булып калу бүген
Җиңел түгел, дустым Корбан.

Әйткән сүзең дөрес синең,
Гел барасың туры юлдан.
Үз фикерең белән яшәү
Җиңел түгел, дустым Корбан.

Кемнәр сатып шөһрәт алган,
Нигә яши илдә ялган?
Кабул итми синең җаның,
Рафис Корбан, дустым Корбан.

Күңелкәең ачык синең,
Изге эшләр бик күп сыйган.
Дусларыңа иңең куеп
Яши белдең, дустым Корбан.

Чиста җанны, саф күңелне
Саклау бүген авыр, туган.
Якыннарны сөендереп,
Дошманнарны көендереп
Яшик әле бергә, туган.

Бу заманга булмыйк корбан,
Рафис Корбан, дустым Корбан.

* * *

Иңемнән биштәр төшмәде,
Юлымны бүлде чикләр.
Гомеремнең юлларында
Очрады һаман читләр...

Көнчеләре аз булмады,
Күрдем сатлык җаннарны.
Якын дуслар күбрәк булды,
Бүлешергә моң-зарны.

Чәчләремә чал керсә дә,
Күңел гел канатлана.
Башкаларның ялгышлары
Нигә соң кабатлана?

Гомерләр кими торса да,
Һәр чорның бар үз яме.
Бүген бәхет – бабай диеп,
Оныгымның дәшкәне.

* * *

Бу дөньяга нигә килгәнемне
Белеп яшим, шөкер, әлегә.
Чарасыздан җаным сызланса да
Керә беләм кеше хәленә.

Бер алманы бишкә генә түгел,
Ун кисәккә әзер бүләргә.
Җылытырга дусларымның күңлен,
Йөрәк җылым әзер түгәргә.

Чарасыздан ишегем шакысалар,
Мосафирны дәшәм өемә.
Кайнар чәем әзер кунагыма,
Гәп кормаса ятлар көенә.

Әгәр килсә кемдер кылыч белән,
Яман фикер булса уенда,
Мин көрәшкә әзер халкым өчен!
Исәр йөрәк тибә куенда...

* * *

Үкенечләр кала үткәннәрдә,
Абынабыз барган юлларда.
Кемнәрнедер кайчак рәнҗетәбез,
Табынабыз ялган идеалга.

Ышанмыйбыз керсез күңелләргә,
Шайтангамы кайчан ияреп.
Кул чабабыз чиста түгелләргә,
Фани дөнья чөнки күгәрек.

Буш вәгъдәләр ява нотыкларда,
Башка фикер гәрчә күңелдә.
Кемнәргәдер бары ошау өчен,
Ялган теләк балдай түгелә.

Баш иябез олы түрәләргә,
Иртәгә дә бар бит яшисе.
Мәдхияләр ага каләмнәрдән,
Килмәсә дә кайчак дәшәсе.

Гали җаннар җирдән иртә китә,
Бәя алмый кылган эшенә.
Дан-шөһрәт ява урынсызга,
Җаен алган әрсез кешегә.

Нигә дөнья шулай яратылган?
Ник яшибез бозып каннарны?
Үкенечләр килә соңлап кына,
Югалткачтын затлы җаннарны.

* * *

Нишләр идем, әгәр син булмасаң,
И каләмем, гомер юлдашым?
Ялгызлыктан күптән сулыр идем,
Синсез калсам әгәр, кордашым.

Нишләр идем, әгәр син булмасаң?
И каләмем, яшә чарланып.
Син булмасаң, хәтәр уйларыма
Бетәр идем күптән чорналып...

Син булганга чыга йөрәгемнән
Әйтеләсе килгән сүзләрем.
Күңелемнән тама энҗе кебек
Әйтелмичә калган серләрем.

И каләмем, сынма авырлыктан,
Әгәр сынсаң, ничек чыдармын?
Каләмкәем, ялгыз итмә мине,
Син булмасаң, мин дә сынармын...

Татарстаннан читтә дә телебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны, милли мәдәниятебезне саклап, аны яшьләребезгә тапшырып яшәүче милләттәшләребез гомер кичерә торган төбәкләр бар. Пермь краеның татар башкаласы дип йөртелгән Барда районы – шундыйлардан. «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының Новосибирск, Пенза, Пермь, Омск өлкәләреннән, Башкортстан, Удмуртия, Марий Эл республикаларыннан, Татарстанның 28 район һәм шәһәреннән килгән вәкилләре катнашында ике көн дәвамында үткән күчмә утырыш-семинары вакытында да бу аеруча ачык күренде.

БАРДА –

Талантлар – район горурлыгы

Барда мәдәният үзәгендә узган күчмә утырыш вакытында кунакларны сәламләгән район башлыгы Хәлил Алапанов та сүзне танылган якташларыннан башлады һәм районның социаль-мәдәни тормышы, балаларга сәләтләрен үстерү өчен тудырылган шартлар белән таныштырды. Бу якларда туып-үскән күренекле композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, педагог Мәсгут Имашев, фольклорчы-галим, милләтпәрвәр Рәшит Ягъфәров, композитор, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Луиза Батыр-Болгари, театр артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Дамира Кузаева, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Сәүбән Чуганаев, Татарстанның халык артисты Гүзәл Уразова, Татарстанның атказанган артисты Чулпан Йосыпова милли рухыбызны, мәдәниятебезне Россиянең төрле төбәкләренә сибелеп яшәүче милләттәшләребез арасында да танытты.

Барда җирендә бүген 10 нан артык милләт вәкиле бер гаилә булып яши. Телебезне саклау максатыннан округта Р.Ягъфәров, М.Җәлил, Г.Тукай укулары үтә. 30 ел элек Барда авылында газета-китап нәшрияты булдырылган. Шушы чор эчендә җирле авторларның 250 дән артык китаплары укучылар кулына килеп ирешкән. Алар арасында әдәби әсәрләр дә, тарихи хезмәтләр дә, аерым кешеләргә багышланганнары да бар. Җирлектә «Барда таңнары» радио-телевидениесе эшли, татар һәм рус телләрендә 90 еллык тарихы булган «Таң», «Рассвет» газеталары дөнья күрә. Мәктәп-гимназияләрдә атнага бер татар теле һәм әдәбияты дәресләре керә. Төбәктәге милли рухны саклауга спортны да кушарга карар иткәннәр. Соңгы елларда Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә спорт ярышлары үткәрелә башлаган. Татар-башкорт иҗтимагый үзәге җитәкчесе Сәлим Назин, Барда «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Нурия Исмәгыйлева, Барда радио-телевидение директоры һәм дикторы Җәүһәрия Габделхакова, район башлыгы урынбасары-аппарат җитәкчесе Илдар Исмакаев, спорт мәктәбе җитәкчесе Рөстәм Батыркаевның кулга кул тотынып бердәм булып эшләве һәрдаим үзен сиздерә. Бүген инде Барда районы җитәкчелеге төбәк халкына спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырылуы турында да мактанып сөйли ала. Районда 76 спорт корылмасы эшли. Һәр балага спорт сарайларында 18 яше тулганчы түләүсез шөгыльләнергә мөмкин.

Районда зурлап Сабантуй, Сөмбелә, Каз өмәсе кебек милли бәйрәмнәребез, борынгы Сөрән суы йоласы үткәрелә. Районда җирлекнең тарихын, фольклор, гореф-гадәтләрен өйрәнү ниятеннән экспедицияләр үтә.

Без – татарлар

Барда районы чигендә кунакларны аеруча хөрмәтләп, җыр-биюләребез белән каршы алдылар. Алар очрашуны: «Күбебезнең паспортында «башкорт» дип язылган. Әмма без үзебезне татар дип хис итәбез», дип башладылар. Гомумән, бу якларда яшәүчеләрдә үзләрен татарга, башкортка бүлү гадәте юк. Пермь краеның кайсы гына районын, шәһәрен алсак та, татарлар үз телләрендә сөйләшә, фикерләшә. Аларның җыр-биюләре, киемнәре дә татарча. Пермь краеның күп кенә округларында «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый үзәкләре эшли.

Бу якның күренекле улы Рәшит Ягъфәров үз хезмәтләрендә татар-башкорт проблемасының Барда җирендә үзенчәлекле чагылыш табуы турында яза. Эш шунда ки, Барда районы халкы үзләрен, без – татарлар, дип йөртсә дә, туган телләре татарныкы булса да, рәсми документларда аларның байтак өлешен башкорт дип язу традициясе яшәп килә. Район халкының моңа әллә-ни исе китми. Татарча укып, туган телләрендә сөйләшеп, милли гореф-гадәтләребезне үз итеп тормыш алып бара. Милли яктан буталчык килеп чыгуның тарихи нигезләрен галимнәр Дәрия Рамазанова, Дамир Исхаков, Фәйзелхак Ислаев бу төбәктә элекке заманның ревизия кенәгәләрендә халыкны башкорт сословиесе итеп теркәүләре, аның исә милләт төшенчәсе белән буталуы белән аңлаталар.

«Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Нурия Исмәгыйлева, район җитәкчелегендә эшләүчеләрнең барысы да, нинди милләттән булуына карамастан, татар телен белүе турында искәртә. «Бардада яшәүче руслар да татарча сөйләшә, татар көйләренә яратып җырлый», – диде ул.

Кадҗмакты – Зиннәтулла хәзрәтнең туган җире

Тукайның әнисе Мәмдүдә абыстай ягыннан туганлык тамырлары Барда ягыннан булуын белә идек инде. Шагыйрьнең бабасы Зиннәтулла Әмиров шушы якның Кадҗмакты авылында туып-үсә, атаклы Солтанай мәдрәсәсендә дин сабаклары ала. Соңрак, белем эстәвен дәвам итү өчен, Татарстан якларына китә, Кышкар мәдрәсәсендә укый, аны тәмамлагач, Өчиле авылына мулла итеп җибәрелә, шунда тормыш кора, кызы Бибимәмдүдә дөньяга аваз сала. Тукайның бабасы да, әнисе дә белемле, алдынгы карашлы кешеләр икәнлеге дә мәгълүм. Аларның тезмә әсәрләр, бәетләр язуга сәләтлелеге дә теркәлеп калган. Зиннәтулла Әмиров Арча районының Өчиле авылында гомер итсә дә, туган ягы белән элемтәсен өзми. Бардалылар ишан булып танылган Зиннәтулланың туган ягына бер кайтуында «Васыятьнамә»сен алып калып, аны күп еллар мәчетләрдә йөртеп укыйлар. Бу «Васыятьнамә»нең күчермәсе хәзер район музеенда да саклана.

Гомумән, Барда төбәгендә Тукайның бабасы бу яклардан булуы турында аеруча яратып сөйлиләр. Күп кенә мәгърифәти-мәдәни оешмалар шагыйрь исемен йөртә.

миллилек утравы

2013 елда Барда районы хакимияте янындагы бакчада Татарстан Президенты Р.Миңнеханов катнашында Г.Тукайның бюсты да куелган. Анда шулай ук шагыйрь әсәрләре геройлары сыннарын да күрергә мөмкин. Барда үзәк китапханә бинасында Г.Тукай музее эшли.

Барданың Г.Тукай исемендәге гимназиясендә без шагыйрьнең бишенче буын туганы, аның кебек җыйнак кына гәүдәле Рафик Акманаев белән дә очраштык. Ул әнисе Әминәдән үзләренең Г.Тукай белән кардәш булулары турында ишетеп үскән, гаиләдә шагыйрь белән туганлыкка кагылышлы язмалар, истәлекләр сакланган, әмма ул елларда шәҗәрәләр төзелмәгән, димәк ки, рәсми яктан расланмаган булган. «Гайнә иле» китабы авторы Әмир ага Фатыйхов Уфа, Казан, Пермь архивларында эзләнгән, Барда округы авылларына барып, өлкәннәр белән сөйләшеп, Әмировлар турында күп кенә мәгълүматлар туплый алган. Табылган, барланган документлар ярдәмендә Зиннәтулла хәзрәт Әмиров шәҗәрәсе төзелә. «Гайнә иле» китабында шулай ук Барда якларындагы бик күп танылган нәселләрнең, шулай ук Әмировларның Казан ханлыгының үзәк өлешеннән күчеп килгәнлеге дәлилләнгән. Әмирхан Әмиров гаиләсе исә Каҗмакты һәм Барда елгаларының Тол елгасына кушылган төбәктә ныклап тамыр җәйгән, тора-бара үзләре бер урам тәшкил иткән.

Музейларда хәтер саклана

Барда һәм Каҗмакты атамалары каян барлыкка килгән соң? Бу риваятьне безгә Барда районының туган якны өйрәнү музеенда бәян иттеләр. Бер хатын-кыз, казлар суеп чистарткач, аны елгага алып төшеп, юарга ниятләгән. Әмма агым көчле вакыт булганмы, казлар агып киткән. «Казым акты, казым акты» дип өзгәләнгән ул. «Ничә казың акты?» – дип сорауга хатын-кыз, «Бар да акты, бар да акты», – дип җаваплаган, имеш.

Музей – Тол елгасы буенда яшәүче татар-башкорт халкы мәдәниятенә багышланган бердәнбер хәтер мәгарәсе. Бүген аның фондында 7500 ядкәр теркәлгән. Экспонатларның бер өлеше Ижау удмурт дәүләт университеты алып барган археологик казу эшләре вакытында табылган. Сугыш кораллары, пыяла бизәнү әйберләре, металл эшләнмәләр – кызыклы ядкәрләрдән. Алар арасында таш гасырга караганы да, тимер чорыныкы да бар. Бакыр кою сәнәгате, Бөек Ватан сугышы бүлекләрендә дә үткәннәргә һәм ватанны саклаган каһарманнарга кагылышлы кадерле истәлекләр саклана. Борынгы бабаларыбызның йорты сурәтләнгән бүлектә игътибарны хатын-кызларның XIX гасыр ахырында киеп йөргән костюмнары җәлеп итә. Күлмәк, камзул, калфак, һәм читекләрдән торган бәйрәм костюмы – гайнә татарларыныкы. Бәрхет калфаклар алтын җепләр белән чигелгән, энҗе, тәңкәләр белән бизәлгән. Хатын-кызларыбызның затлы калфаклары, бизәлешенә карап, «тәңкәле» (әбиләрнеке) һәм «энҗеле» (кызларныкы) калфакларга бүленгән. Гаиләнең җитеш тормышта яшәү-яшәмәве хатын-кызның киеменә карап тәгаенләнгән. Яка чылбырындагы асма бизәкләр санына карап яшь аермаларын чамаларга мөмкин булган. Әйтик, яшьрәкләр бердән – дүрткә, өлкәнрәк хатын-кызлар уникегә кадәр асма бизәк йөрткәннәр. Хәзерге вакытта Барда түбәтәе Пермь краеның матди булмаган мәдәни мирасы объектлары реестрында теркәлгән. Ул конус формасында дүрт өлештән тора. Алар кешенең балалык, үсмер, яшьлек, картлык чорларын белдерә. Мәдәният йорты бинасының бер бүлмәсендә «Барда түбәтәе» музее булдырылган.

Бергәләп эшләү күңелле

Соңгы елларда Барда һәм Казан арасында аралашу җирле татар-башкорт иҗтимагый үзәге, «Ак калфак» оешмасы бүлекчәсе булдырылганнан соң, аеруча көчәйгән.

«Милли үзаңы үскән, телебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне белгән бала тәрбияләү һәркайсыбызның бурычы. Шуңа да иҗтимагый оешмалар эшчәнлекләрен мәктәпләр белән берлектә алып бара», – ди бүлекчә җитәкчесе Н.Исмәгыйлева. Хәзерге вакытта оешма 13 авылда актив эшчәнлек алып бара. Җирлекләр еш кына, яшьләрне тәрбияләүдә үз өлешебезне кертәсебез килә, оешмагызда булыйк әле, дип шалтыраталар. Шунысы да кызыклы: бу якларда аккалфаклыларның авылара очрашуы традициягә әверелеп киткән. Җыелып күргәзмәләр оештыралар, эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар, киңәш-табыш итәләр, осталык дәресләре үткәрәләр. Бу авыл халкы өчен дә милли бәйрәмгә әверелә. «Авылара очрашулар безне якынайта», - ди җитәкче. Шул ук вакытта аккалфаклар үзләренең эшчәнлеген мәктәп-гимназияләрдә дә җәелдергән. «Ак калфак» укучы кызлар», «Барда кызчыгы», «Барда малае» бәйгеләрен үткәрүдә ата-аналар ярдәм итә икән, бу инде аларның үзләренең дә милли мәдәниятебезне хәтерләрендә яңартуы, дигән сүз. Милли бәйрәмнәр уку йортларында, балалар учреждениеләрендә аларның яшь аерымлыкларына карап алып барыла. Кечерәк сыйныфларда укучылар арасында – Нәүрүз, V-VI да – Сабантуй, Сөмбелә, VII дә - Нардуган, VIII дә – «Уйнагыз гармуннар», зуррак сыйныфларда – Аулак өй, Каз өмәсе һ.б. бәйрәмнәр үтә. Шулай итеп бала мәктәптә укыган чорда күп кенә милли йолалар белән танышып чыга.

«Балалар бакчаларында, мәктәпләрендә милли почмаклар булдыру, кече яшьтәгеләр белән милли уеннар уйнау, җыр биюләр гадәткә керде, аңа эти-әниләр дә кушылды, милли ашлар пешерү дә җанланды», – ди Н.Исмәгыйлева.

Мәктәптә милли сәнгатебез гөрли

Барданың Г.Тукай исемендәге гимназиясе кунакларны зур җанлылык белән каршылады. Укучыларның милли киемнәренә дә, бию-җырга осталыкларына да хәйран калырлык! Соңрак мәгълүм булганча, бирелә укучыларны җыр һәм бию сәнгатенә өйрәтеп кенә калмыйча, аларда милли сәнгатебезгә, мәдәниятебезгә мәхәббәт тә тәрбиялиләр. 790 бала белем алган уку йортында «Чишмә» фольклор, «Көмеш кыңгырау» вокаль ансамбльләре, «Алтынай» хореография коллективы эшли. Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты дәресләре барлык сыйныфларда да укытыла. Укучыларның мондагы «Хәзинә» этнография музеенда туган телебездә экскурсия үткәрүләре дә аккалфаклыларның күңеленә хуш килде. Яшь «артистлар» кунакларга Тукай әсәрләренә нигезләнеп язылган «Серле урман» пьесасын да тәкъдим итте. Идиат Аширов шигыренә композитор Луиза Батыр-Болгари язган «Барда» җыры исә гимн буларак яңгырады.

Мәктәптә Тукай рухы һәрдаим сизелеп тора. Әйтик, шагыйрь әсәрләреннән төзелгән коллаж янында класстан тыш чараларны уздыру күркәм гадәткә әверелгән. «Мин татар баласы» бәйгесе, Г.Тукайның туган көнендә шигърият бәйрәме дә бирелә уза.

* * *

Аккалфаклылар игътибарына тәкъдим ителгән күргәзмәләр, сәнгать коллективлары чыгышлары, Барда халык театрының драматург Хәбир Ибраһим әсәре буенча куйган «Ак каен күзе» спектакле, Атнягузи авылы фольклор коллективының «Бәби туе», Иске авыл фольклор ансамбленең «Урак өсте», Ирен татарлары үзешчәннәренең «Бала каршылау» сәхнәләштерелгән күренешләре, «Гайнә җире» фольклор ансамбле, «Бәйрәм» җыр һәм бию ансамбле, Барда балалар сәнгать мәктәбенең балалары чыгышлары, уку йортының Пермь крае күләмендә үткәрелгән конкурста «Иң яхшы мәктәп» дигән дипломга ия булуы һ.б. – бу якларда милли сәнгатебез һәм мәдәниятебезнең сакланып калынуы һәм ул түкми-чәчми балаларга, яшьләребезгә тапшырылуының чагылышы. «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова ассызыклап үткәнчә, һәр җирлекнең үз үзенчәлеге бар. Без аны белергә һәм балаларга сеңдерә барырга тиешбез. Бардалылар исә Россиянең төрле төбәкләреннән килгән кунакларга үзләренең фольклоры аша тирән тарихны, халыкның элек-электән килгән яшәешен күрсәтеп бирә белделәр.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Мәдәни җомга
27 май
№20, 2022

БЕР ТАТАР ХАТИРӘСЕ

Надежда ДУРОВА

Казан каласын узгач, куе урман башлана, шомлы карурман – керсәң чыга алмаслык. Урман аша олы юл салынган, ләкин кышын ул юл тарая, сукмак шикелле генә булып кала. Урманга төн төште. Тирә якта шылт иткән аваз юк, бары тик картаеп бара торган ямьченең ара-тирә атына кычкыргалаганы һәм аның йокы китергеч, изрәткеч җырлавы гына ишетелә. Бу агай мине Казаннан ук алып чыккан иде.

– Һәйдә, һәйдә, Хәмидулла! – дип туктаусыз кабатлый ул сузынкы, моң тулы тавышы белән үз халкы чыгарган җырын.

Бу озын бер көйнең кушымтасы булса кирәк. Сәгатьләр буена яңгыраган бу җыруны тыңлап аргач, сорадым:

– Кем ул Хәмидулла, Якуб ага, колагыма чикерткә булып оялады синең бу җыруың.

Якуп ага кузласында утырган килеш, борылып, шелтәле караш ташлады:

– Кем ул Хәмидулла, дисең син! Хәмидулла ул безнең ырудагы бөтен ир-егетләрдән дә мәһабәт бер җегет иде!

– Синең ыруыңнанмы, Якуб ага яки бөтен татар ыруыннанмы?

Якуб җавап бирмәде. Ачуландымы ул, белмим, әмма чал татар карурманның куелыгына төксе карап, тирән көрсенде. Мин аның авыр уйларына катышмадым. Шинелем белән башымны каплап, йокларга дип кырын яттым. Кинәт Якуб минем тарафка борылды да:

– Барин! –диде. – Без хәзер әнә шул Хәмидулла озак качып яткан, шунда каңгырап яшәргә тырышкан карурман аша барабыз!.. Ул бу юлдан узган бөтен юлаучыларның котын алган җир. Аны шушыннан эзләделәр, эзәрлекләделәр, һәм, ниһаять, тотып алдылар!.. Бичара Хәмидулла! Мин аны танымадым, үз күзләремә үзем ышанмадым. Ул яхшы күңелле, намуслы, вөҗданы чиста, һәйбәт бала, кадерле туган, тугры дус!.. Ике беләгенә дә тимер богау ураганнар!.. Кеше талаганы өчен!.. Менә сез ничек уйлыйсыз, барин, талаумы инде ул, җинаятьмени ул, нинди разбуй булсын?.. Беләсегез киләме, барин?

– Ярый, Якуб ага, сөйлә.

– Мин аның турында сөйләргә яратам; гаҗәпләнәм мин аңа һәм кызганам, аны аталарча кызганам, аның бичара хәлен аңлыйм... Әйе, мин Хәмидулланы үз улым кебек ярата идем!.. Аңа унҗиде яшь чакта мин икенче хатыным өчен калым түләп, хатынымның атасы йортына, шул авылга күченеп килдем... кайнатага ярдәмче булырмын, дидем. Хәмидулла атасының йорты кайнатам йорты белән рәттән иде. Миңа ул чакта кырык ике яшь иде, балаларым юк, мин шушы тәвәккәл җегеткә җаным белән тартыла идем. Ул да мине бик якын күрә, атасы кебек якын күрә иде. Ул башкалардан аерылып торучы мәһабәт җегет кенә түгел, оста мәргән, ат җене кагылган оста җайдак та. Кайчакта ул кыргый атны кулга ияләндереп, тезгененнән тотып миңа алып килә һәм әйтә иде: «Кара, Якуб ага, минем менә шушындый атларга гына атланып йөрисем килә! Юаш аттан ни файда? Юаш атларның булганыннан булмаганы яхшы!» – дип көлә иде.

– Ни өчен син, Хәмидулла, безне дулый торган атка атландырып, муен сындырыбызны телисең? Сиңа ярый ул, син яшь, куәтле, шәп атменәр-җайдак, ә мин карт инде. Нишлим андый ат белән?

– Хак! Мин ул турыда уйламаганмын, – дип шаян Хәмидулла сөекле атын чирәмгә утларга җибәрә торган иде.

Ләкин вакыт килеп җитте, аны дулый торган ат та, тыгыз керешле җәяле ук та кызыксындырмый башлады. Тоякларыннан ут чыгара торган кыргый атлары, ялларын тузгытып, таулар, үзәннәр арасында очып йөри башлады. Ә Хәмидулла аларны тотып сыртларына ияр салырга уйламый да, аңа хәзер өйдә утыруы рәхәтрәк. Аратирә ул Зөһрәләр яшәгән өй турыннан узгалый. Зөһрә авылның иң бай кешесенең кызы иде. Зөһрә каратут йөзле, нәфис-зифа буйлы, шомырттай кара кашлы, кара күзле, гәрчә, татар кызлары арасында андыйлар бик еш очрый, аларның барысы да дип әйтерлек, кара күзле була. Ләкин Зөһрәнең каракучлыгы ул серле-сихерле тутлылык иде! Ул тутлылыкта Хәмидулланың йөрәген рәхимсез рәвештә сызландыручы сер бар иде...

– Якуб ага, Хәмидулла сөеклесе белән очрашкандыр бит? Сезнең татар кызлары ир-егетләрдән кача бит, – дидем.



– Ләкин кызлар ошарга теләгән егетләреннән качмый; монда үзләрен күрсәтер өчен гаҗәеп оста алымнар бар...

– Кызы өчен күпме калым кирәклеген син Зөһрәнең атасыннан сорадыңмы соң? – дим Хәмидуллага.

– Сорадым, – ди.

– Ул нәрсә әйтте соң?

– Зөһрә өчен атасы шундый калым таләп итә ки, авылда андый калымны түли ала торган бай юк, ә минем нәрсәм?

– Шулай булгач, син аның янында чуалма инде, Хәмидулла... Аңла син үз хәлеңне, аны онытырга тырыш, үзеңне үзең җиң. Берәр шөгыль тап, мәсәлән, Казанга кит.

– Чыннан да,– диде Хәмидулла күңелсез генә. – Әти мине Казанга җибәрә, халат-чикмән сатар өчен, язга чаклы шунда сату итәрмен.

– Кайчан китәсең?

– Бер атнадан.

Моңа бик шатландым, Казанда, зур шәһәрдә, олы мәшәкатьләр арасында бераз онытылыр, яшь татар җегетнең гыйшык-мыйшык белән шөгыльләнергә вакыты калмас, дип сөендем. Әмма мин Хәмидулланы белмәгәнмен икән шул!

Ул Казанга китте, еш кына атасына хат яза иде, һәр адымы турында хәбәр итә, файда күргән акчасын атасына җибәреп тора, авылга кайтырга ашыкмый һәм Зөһрә турында ләм-мим, бер сүз дә язмый. Мин куанам, аерылышып тору үз эшен башкара, дип уйлый идем, җегет тынычланды, ләкин Хәмидулланы белеп бетермәгәнмен икән!

– Сәүдә эшләре белән шөгыльләнгән чакта, ул авылын сагынган, ямансулаган, борчылган, язның беренче чәчәкләрен өметләнеп көткән, бичара, ул туган нигезенә ашкынган. Гүзәл кыз Зөһрәнең атасы Габдерәшиткә мул калым тәкъдим итүчеләр күп иде. Кызның бәһасе арта барган саен Габдерәшит картның нәфесе дә арта иде. Ниһаять, ерак шәһәрдә яшәүче бер яшь бай сәүдәгәр Зөһрәнең атасына кеше ышанмаслык калым вәгъдә иткән. Габдерәшит кызын сәүдәгәргә бирергә риза була, кызны бирәләр, никах укыталар. Шул кичне Зөһрә яшь кияү бүләк иткән кыйбатлы хәситәсен күз яшьләре белән чылатып бетергәндә Хәмидулла авылга кайтып төшә.

– Яшь җегетнең йөзендә бернинди кайгы-хәсрәт билгесе күренми, кызып китү дә, борчылу да юк, ул авыл капкасыннан кергән чакта мин беренче булып аны күреп алдым. Аның өчен үтергеч бу яңалыкны минем авыздан ишетсә, Хәмидуллага җиңелрәк булыр, дип уйладым. Аталарча сак кына, иплән кенә Зөһрәнең башка кеше никахында булуын әйттем. Ул бәс кебек агарды, бөтен тәне белән калтырый башлады. Арбасындагы балтасын кулына алды, ләкин шундук айнып та китте һәм гаҗәпләнүемә күрә, ул бик тиз сабырланды, салкын канлылык белән сүземне тыңлап бетерде. Аңа Зөһрәнең ничек җылаганын, ничек карышканын сөйләдем. Җегетнең сабырлыгына, кинәт яман уеннан кире кайтуына куандым. Ләкин, барин, Хәмидулланы начар белгәнмен икән шул!

– Зөһрә төнлә никахлы иренең ятагыннан юкка чыга, ә Хәмидулла атасының сәкесеннән гаип була; икесенең дә кая киткәннәре нәмәгълүм иде. Зөһрәнең никахлысы, бай кияү, акылдан язарлык хәлгә килде; ул калага китә дә бу җинаять турында прошение яза. Суд килде авылга, качакларны эзләүләр башланды. Ниһаять, билгеле булды: Хәмидулла үзенең Зөһрәсе белән карурман уртасында, ике су арасындагы киң атауда яшәп ята икән. Барин, без менә шул атау турыннан узып барабыз.

Мин ихластан шатландым аларның шулай качкын булып яшәвенә, бер-бер хәл килеп чыкмагае, дип бик борчылган идем, алар турында ишеткәч, тынычландым. Алга таба нәрсә булыр, кыш җиткәч кая барыр алар? Нәрсә ашар, нәрсә киярләр? Кышкы зәмһәрир суыкта урманда яшәве, ай-һай!.. Ул арада Зөһрәнең атасы белән кияү кеше конвой белән, туганнары белән көн саен урманны айкый, качкыннарны эзли чыгалар. Земская полиция тотынды Хәмидулланы эзләргә, аның турында имеш-мимеш йөрде, ул качкын булып, узгынчыларны талый икән, имеш, җә аларның ипиен таләп итә, җә акчаларын талап ала икән, дип нахак яла яга башладылар. Хәмидулла андый түгел, бу – бөһтан, яла ягу бу, дидем. Ул кешегә зыян сала торган кеше түгел. Аларны эзли торгач, җәй дә узып китте, көз дә җитте. Халык инде Хәмидулланы разбуйник дип атый башлады, гәрчә аның беркемгә дә кагылганы булмады, алган очракта да ул сорап ала, әз генә ипи алырлык микъдарда гына акча ала торган була. Ә земская полиция белән пүнәтәйләр разбуйник Хәмидулланы табарга тырышты! Яңгырлы бер салкын төндә, ай яктысы булмаган чакта, тирә-як караңгы, ике адымнан берни дә күренми, мин озаграк кич утырдым. Бик тә ямансу булып китте, кайгылы уйларым башымда кайный, ул уйларым Хәмидулла турында иде. Якын кешем турындагы хәсрәтле хикәянең ахыры якынлаша иде, ахрысы. Кыш барысын да хәл итәр дә, аларның тәкъдирен тәмамлап та куяр, дим. Коточкыч хәлләр! Ниһаять, мин йокларга яттым, күземне йомдым, йокыга да киттем шикелле, шулчак тәрәзәгә кемдер сак кына чиртте һәм шыпырт кына таныш тавыш ишетелде, бу – качкын Хәмидуллам иде. Шатлыгымнан сикереп тордым. «Хәмидулла» дип кычкырдым да сүзсез калдым, әйтәсе сүзләрем авызыма ябышып калды, без тәрәз аша сөйләштек, бичараның калтыранган кулын кыстым. Мин аны җылы өемә чакыра алмыйм, ашата-эчертә алмыйм. Йөрәгем ярылырдай булып тибә. «Хәмидулла, кач! Авыл тулы пүнәтәйләр, сине исправник үзе эзли! Кач, яшерен, тиз бул!» – дидем.

– Чык, Якуб ага, чык әле син! – диде Хәмидулла чак ишетелерлек итеп. – Әйдә минем белән авыл читенә, урманга хәтле барыйк. Сөйлисе сүзләрем бар.

Мин өйдән чыктым, кулга кул тотышып, авылдан басуга чыктык. Урман бер чакрымда гына, без урманга кердек. Мин туктап калдым.

– Юк, агам, мин синең ярдәмеңә мохтаҗ. Зинһар, миңа ярдәм ит сана, бәлки синең бу соңгы ярдәмеңдер, – дип ялвара дустым.

Сөйләр сүз табалмыйча, мин Хәмидуллага ияреп барам. Күзгә яңгыр үзәккә үткәзеп ява, йөзгә бәрә, киемгә сылана, житмәсә ашыгычлык белән мин башыма киярга дә онытканмын. Ярты сәгатьләп бардык.

(Дәвамы киләсе санда).

Рабит БАТУЛЛА тәрҗемәсе.

Татар көйләрен гавай гитарасында яңгыраткан бердәнбер татар музыканты Сәгыйть Алиевнең тууына 115 ел.

● Камил Басыйров (сулда), Сәгыйть Алиев, ..., Рәшит Ваһапов, алда – Зифа Басыйрова. Сталинабад шәһәре.

Бердәнбер гавайчы

Сәгыйть Алиев 1907 елның 31 маенда Томск шәһәрендә туа. 1928 елда берьюлы Томск татар педагогика техникумын һәм Томск музыка техникумын тәмамлый һәм эшкә Новосибирск шәһәренә юллама ала. Анда 1928-1931 елларда 6 нчы номерлы татар мәктәбендә музыка укыта. Бер сезон Новосибирск өлкә Татар күчмә театрында музыка җитәкчесе булып эшли. 1932 елда театр ябыла һәм С.Алиев «Азат Себер» газетасына җаваплы сәркатип булып эшкә күчә. Анда ике ел эшләгәч, 1934-1935 елларда Караганда өлкәсе Татар драма театрында музыка җитәкчесе, 1935-1937 елларда Новосибирск радиосында музыкаль мөхәррир һәм тапшырулар оештыручы, Томск татар педагогика училищесында хор һәм башка музыка түгәрәкләрен җитәкли. 1937-1940 елларда С.Алиев Казанда Татар радио комитетында музыкаль тапшырулар редакциясе мөхәррире була.

1941 елда С.Алиев Татар дәүләт филармониясенә Халык уен кораллары оркестрына эшкә килә. Сугыш башлангач фронтка китә, Берлинга кадәр җитеп, Казанга әйләнеп кайта. «Ватан сугышы» ордены, «Сугышчан батырлыклар өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алу өчен» һ.б. медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң ул үзенең эшчәнлеген янә филармониядә дәвам итә, оркестрда домрачылар төркеме концертмейстеры һәм эстрада бүлеге солисты була, Рәшит Ваһапов бригадасында музыкант буларак илебез һәм элеккеге Советлар Союзы буйлап гастрольләрдә йөри.

С.Алиев 1995 елның 12 февралендә вафат була. Казанның Яңа татар бистәсе зиратында җирләнә. Филармония музее архивында Сәгыйть Алиевнең фоторәсемнәре, тәрҗемәи хәлен сурәтләгән, үз куллары белән язылган язмасы саклана, саргая башлаган кәгазьләрдә - тәҗрибәле музыкантның иҗат һәм тормыш мизгелләре.

«Татар дәүләт филармониясенең концерт бригадалары Себер шәһәрләрендә яшәүче татарлар янына да еш килә иде. Мәсәлән, мандолиначы Исмәгыйль Һилалов җитәкчелегендәге бригаданың бездә чыгыш ясаганы хәтердә саклана. Аларны күреп минем дә Казанга киләсе, шунда эшлисе килде. Шуннан үземнең көчемне сынап карыйм дип Казанга күченеп килдем, бик күп музыка әһелләре белән таныштым. Торган саен җанны бер сорау газаплады: ни өчен татар башкаручылары арасында саксофон яки гавай гитарасында уйнаучы яки өйрәтүче кеше юк икән? Шуннан гади җиде кыллы рус гитарасы сатып алдым, аны дүрт кыллыга калдырып, скрипка яки мандолина урынына көйләдем дә, үзләштерә башладым. Ышаныч белән уйнарлык башкару дәрәҗәсенә ирешкәч, радиокомитет җитәкчеләренә микрофон алдында чыгыш ясарга тәкъдим иттем, беренче тапкыр гавай гитарасы аша татар халык көйләре шул чакта яңгырады. Көчәйткечсез уйнаганда аның тавышы бик зәгыйфь, шуңа күрә микрофонга уйнарга туры килә иде. Радиотыңлаучылардан «Бу нинди музыка коралы?» дигән сораулар белән хатлар килә башлады. Мин татар композиторлары Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Нәҗип Җиһанов, Әнвәр Бакиров, Башкортстаннан Таһир Кәримов, Мәсәлим Вәлиев, Казахстаннан Латыйф Хәмиди... әсәрләрен үзләштердем. Хәтта неаполитан халык көе «Санта Лючия», совет кинофильмнарындагы музыка әсәрләре дә репертуарымны баетты. Бу бигрәк тә Ватан сугышыннан кайткач, Г.Тукай исемендәге Татар филармониясендә эстрада артисты булып эшләгән чорда булды.

Радиокомитетта музыкаль мөхәррир булып эшли идем. Яңадан-яңа программалар төзү өчен эзләндем. Мәскәүдә укып кайткан татар опера театры солистларын концертка чакыра идем. Алар арасында талантлы җырчылар Усман Әлмиев, Мәрьям Рахманкулова, Галия Кайбицкая, Мөнирә Булатова матур тавыш, киң репертуарлары белән концерт программаларын төрләндерде.

1941 елда көзен Мәскәүдә Татар декадасы булырга тиеш иде, барлык сәнгать көчләре шуңа хәзерләнә башлады. Татар дәүләт филармониясендә татар хоры һәм бию коллективы оешты, аның сәнгать җитәкчесе итеп Зөләйха Әхмәтова билгеләнде. Шулай ук халык музыка кораллары оркестры да җыелды. Мине шул оркестрның домра төркеменә концертмейстер итеп филармониягә эшкә чакырдылар. Программаны Татарстан хөкүмәте башлыклары, Мәскәүдән танылган дирижер Евгений Мравинский килеп тыңлады.

22 июнь көнне, якшәмбе булуына карамастан, филармониягә җыелдык. Радио аша коточкыч хәл – Бөек Ватан сугышы башлану турында хәбәр ишеттек. Декадага әзерлек эше туктатылды, музыкантлар фронтка алынды. Мин дә 1941 елның декабрендә хәрби военкоматка килдем, Казанда оештырылган 146 нчы пехота дивизиясе белән сугышны Смоленск өлкәсендә башлап, Калинин өлкәсен азат итүгә күчтем, аннары Псков өлкәсенә кергән Остров шәһәрен азат итүдә катнаштым. Безнең дивизиягә Островский исеме бирелде, соңыннан Эстониянең Таллин шәһәрен азат иткән өчен дивизиягә Кызыл байрак ордены бирелде, соңыннан Польша ягына күчерделәр. Варшаваны азат итүдә катнашып, Берлинга кадәр барып җиттек, дивизиябезгә Суворов ордены тапшырылды.

1945 елның октябрь аенда Казанга кайтып, Татар филармониясенең эстрада бүлегендә скрипкада һәм гавай гитарасында башкаручы солист буларак эшемне дәвам иттем. Миңа халык артисты Р.Ваһапов бригадасы белән 15 ел аерылгысыз эшләргә насыйп булды. Рус эстрада бригадалары белән дә шәһәрдәге югары уку йортларында, мәдәният сарайларында, ял йортларында чыгышлар еш була иде. 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаштым. Лаеклы ялга чыкканчы филармониядә хезмәт иттем. Сәгыйть Алиев (1988 ел)».

С.Алиев турында аның сәхнәдәшләре язып калдырган истәлекләр дә бездә күп саклана. Шуларның кайберләренә күз салыйк.

Татарстанның атказанган артисты Әзәл Яһүдин («Артист язмалары» истәлек кулъязмасыннан): «Безнең электрогитарада уйнаучы дустыбыз Сәгыйть Алиев һәрвакыт чәчен кырып, ялтырап торган баш белән сәхнәгә чыгып, сәхнәне балкыта иде. Ә җәйге гастрольләрдә концертлар күбесенчә ачык һавада үткәрелә бит. Ә ут яктысына бөтен дөньядагы черки-чебеннәр туплана һәм безгә шактый комачаулыйлар иде. Бер концертта Сәгыйть дустым ялтырап торган баш түбәсенә черки килеп кунды, ул башын селкеп караса да һич китмәде. Сәгыйть дус уенын бозмый, тәки әсәрне ахырга кадәр уйнап чыкты бит. «Менә нинди чыдам безнең Сәгыйть дус!» – дип мактадык үзен».

Россия һәм Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Айрат Арслановның истәлеге:

«...1968 елның кышында Питрәч, Лаеш якларына концертлар белән чыктык. Концерттан соң фатирга Сәгыйть ага белән бергә керәм. Сәгыйть ага үз өендәге кебек хуҗаларча карана, начар эшләүче радиоалгычны төзәтергә керешә, бераз маташа торгач, радиоалгыч ачык сөйли башлый. «Апасы, бу стена сәгатегез нишләп йөрми?» – дип сорый. Апа: «Ул күптән туктаган инде. Авылга килгән мачтырларга күрсәтеп караган идек, алар да булдыра алмады. Чоланга чыгарып әләсе бар үзен», – ди. Сәгыйть ага елмаеп кына: «Кая, алып карыйм әле, нинди төзәтеп булмаслык сәгать икән ул?» – дип сәгатьне актара башлый. «Машина маегыз бармы, апасы?» – дип тә сорап куя. Сәгыйть ага бер сәгатькә якын маташып, сәгатьне майлап, тузаннарын сөртеп кире урынына элеп куя. Ходайның хикмәте, сәгать келт-келт итеп йөреп китә. «Афәрин, Сәгыйть ага, алтын куллы икәнсең!» – дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калам. Ә ул, мыек астыннан гына елмаеп: «Шулай энекәш, җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз!» – ди. Икенче бер авылда Сәгыйть ага хуҗаларның күптән эшләмәгән тегү машиналарын төзәтеп бирде. Безне тагын якын туганнары кебек хөрмәт иттеләр. Менә шундый кешелекле, кулыннан һәр эш килә торган шәхес, оста музыкант иде Сәгыйть агабыз!»

Татарстанның халык артисты Флүрә Сөләйманова: «Сәгыйть абый бик тыныч холыклы, тәртипле кеше һәм үз һөнәренең остасы иде. Концертларда аның белән кызык хәлләргә дә очрый идек. Концертларны алып баручы, нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов аның чыгышларын тагын да кызыклы итә иде. Аларның икесенең дә хатыннары Сара исемле иде, шуны кызык итеп Фәйзи абый болай дия иде:

«...Синдә – Сара, миндә – Сара,
Бу тормыш кая бара?... »

Аннан Сәгыйть абыйның чәче юк иде, Фәйзи агайның да соңгы елларда чәче сирәкләнде. Ул аңа сәхнәдә «Мә, Сәгыйть дус, чәчеңне тарап җибәр» дип, кесәсеннән тарак чыгарып бирә иде. Бу шаярудан соң халык гөр килеп, аның чыгышларын тагын бер кат дәррәү алкышлый иде».

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәнис Гыйльметдинов:

«Миңа филармониядә эшләгәндә Сәгыйть абый белән Ульян өлкәсенә, Куйбышев өлкәсенең Камышлы авылына гастрольгә чыгарга туры килде. Анда күренекле җырчылар Җәваһирә Сәләхова һәм Рафаэль Ильясов белән чыгыш ясадык. Матур аһәңле гавай гитарасында Сәгыйть абый искиткеч матур, моңлы итеп уйный иде. Концерт программасының бер бүлеген аның уены били иде. Мин аңа «Ай, былбылым» татар көенә аккомпанимент ясый идем. Халык Сәгыйть абыйның чыгышларын бик яратып, җылы кабул итә иде. Аның гавай гитарасы икәү булган, гастрольдә чакта ул шуның берсен миңа сатып алырга тәкъдим иткән иде. Мин бу уен коралына бик кызыксам да, ул чакта яшьлегем белән, бу тәкъдимне кире кактым. Чөнки бу коралның тавышы зәгыйфь, анда уйнау өчен үзең белән магнитофон колонкаларын алып йөрергә кирәк иде, әле баян да бар бит. Аннары үкендем, әлбәттә. Кызганыч, Сәгыйть абыйдан соң, татар музыкантлары арасында бу уен коралында уйнаучы булмады».

Алсу ХӘКИМОВА.

Мәдәни җомга
27 май
№20, 2022

● М.Гәрәев портреты. Рәшит Нурмөхәммәтов эше. 1986 ел.

● М.Гәрәев сугышчан заданиедән кайткач. Апрель,1943 ел.


● Хатыны Галина Мигунова һәм М.Гәрәев. 1944 ел.

МУСАЛАР – ТАТАР,

(Атаклы очучы Муса Гәрәевнең тууына 100 ел)

Башкортстан халкы 9 июльдә Бөек Ватан сугышында ике мәртәбә Советлар Союзы Каһарманы дәрәҗәсен алуга ирешкән һәм «ут күрше» республика өчен бердәнбер булган Муса Гайсә улы Гәрәевнең тууына 100 ел тулуны билгеләп үтәргә әзерләнә. Сүз дә юк, әлбәттә, аны 77 ел буена «башкорт» милләте вәкиле, «башкорт халкының каһарман улы», дип, күкрәк сугып яшәде бит алар. Чөнки, башкорт мөтәгалимнәречә, Илеш районы халкын гәрәй, кыргыз, елан, бүләр, янәй, елдәк ыруларына караучы «башкорт» вәкилләре тәшкил итә. Үзе татар булган көе, башкорт халкының атаклы карагруһчысына әверелгән Мидхәт Шакирҗанов һәм шул дилбегә тоткан чорда 25 ел буе Илеш районы партия комитетын җитәкләгән (анысы да «чи татар») Тәлгат Рахманов «тырышлыгы» белән район халкының 80 проценты «башкорт» милләте вәкиленә әйләндерелде. Җир шарының теләсә кайсы почмагында халыкларның үсеш күрсәткече бер гасыр дәвамында 1,5 тапкырдан артмаса, соңгы 50 елда «ут күрше»дәге «башкортлар» 7 мәртәбә үстерелеп, «дөньякүләм рекорд» куйды!

Күршедәге бертуган милләт белән тарткалашу күңелне үтә әрнеткеч шөгыль булса да, берничә дәлил белән каршы төшмичә дә ярамый. Башкортларның үтә карагруһчы мөтәгалимнәре XXI гасырга аяк баскач та урта гасырлар үлчәменнән ерак китә алмый һәм, әнә, һәрбер район чигенә «ыру баганалары» утыртып чыкты. Илеш районы чигендәге «тәре баганаларына» гәрәй ыруының да исемен чәпәп куйганнар. Бердән, Гәрәй – ыру гына түгел, ә Кырымда, Себердә, Мәскәү төбәгендә һәм Идел буенда яшәүче бөек татар милләтенең нигез ташын һәм зур өлешен тәшкил итүче бик дәү кабилә ул. 1380 елларда Туктамыш хан фәрманы буенча һәм Карабәк-Габдулла хан кул

● М.Гәрәевнең әтисе Гайсә һәм әнисе Гөлнәфисә.

астында 17 мең арбага төялеп Кырымнан кузгалган һәм Кавказ итәгендә, Идел тамагында, Сакмар, Җаек елгалары буенда яшәүче мөселман вәкилләрен куша-куша элеккеге Болгар дәүләте җирләренә килеп утырганда аларның гомумсаны ким дигәндә 170-200 мең чамасы тәшкил иткән. Башкорт мөтәгалимнәре күз йоммакчы, әмма шушы, Гәрәй кабиләсе дип аталучы күчмәннәрнең саны ул чорда Урал тавының төньяк өлешендә һәм аның аръягында гомер сөргән башкортлардан гаять дәрәҗәдә күбрәк булган! Ә сан ягыннан күбрәк булган халык берчакта да кечерәк милләтнең нигез ташы булып тора алмый! Ата милләтче Салават Хәмидуллин атлы «галимгә» зур сәхнәдән ярырга туры килгәне бар: «Гәрәй кабиләсен башкортныкы итүдә генә тукталмагыз инде, кызгач-кызгач, гәрәйлеләр тәүге канат ярган Кырым атавын да башкортныкы итеп дәгъва кылыгыз сез!..»

Гәрәйлеләр һәм аларга Аксак Тимер талавыннан туйганга күрә ияреп килгән кыргыз, кыпчак ыруы вәкилләренең бер өлеше әнә шул XIV гасыр ахырында, XV гасыр башында ук Ык, Сөн, Агыйдел, Баҗы, Чәрмәсән елгалары буена урнаша, тора-бара Нократ елгасы, Арча төбәге, хәтта Урал буендагы Ишембай тирәсенә дә барып җитә.

Икенче дәлил - Мәрҗани исемендәге Тарих институты 2020 елда нәшер иткән «Татары Уфимского уезда» китабына гына күз йөгертик. Районга исем биргән Илеш, бүген үзәк булып торучы Югары һәм Түбән Яркәй, Иске һәм Яңа Нәдер, атаклы каһарман Муса Гәрәев туган төбәктәге авыл советы үзәге Олы Бишкурай, исеме үк «морзаларныкы» дип торучы Кенәз-Елга, Хуҗа, Баҗытамак, Шәдәле, Чуй-Әтәс, Манчар, Каенлык, Ябалак, Кушбакты, төп «әти-әнисен» Әгерҗе районында калдырып 1700 елларда «башка чыккан» Исәнбай, 1600 елларда ук волость үзәге булган Иске Кыргыз, Сөн елгасының сулъяк ярында, Актаныш районында адашы булган Аккүз, нәкъ шул рәвешчә, күрше ике районда да бер үк исем йөртүче һәм 300 еллыгын уздырган Теләкәй, Тукай һәм Лениногорск районнарындагы авылларның адашы Иштирәк, Тупый, Ирмәш (бер тарихи документта 1707 елда ук телгә алынган Ирмәш Урмашев соңрак күрше Төкәй авылында «баш-

● М.Гәрәевнең сугышчан бүләкләре.

● Мусаның әнисе һәм апалары Таш-Чишмәдәге йорт янында. 1930 еллар.

● Югары Яркәй музеендагы төп стенд.

● М.Гәрәев – Энгельс авиация мәктәбе курсанты.

МУСАЛАР БАТЫР БУЛА

● М.Гәрәев – Башкортстанның ДОСААФ рәисе.

● Ике мәртәбә Советлар Союзы Геройлары Л.Беда, М.Степанищев һәм М.Гәрәев (уңда) өч мәртәбә Каһарман И.Кожедуб белән. Мәскәү, июнь, 1945 ел.

● Пионерлар белән очрашу. 1973 ел.

корт» старшинасы булып тора, ә аның улы Мерәс Ирмәшев әүвәл Сөн аръягындагы волость үзәге Байсар авылына күчеп утыра, 1738 еллар тирәсендә аның Байлар волостенда – бүгенге Тукай районындагы Мерәс авылын нигезләве мөмкин), исеме үк әйтеп торган Татар Мәнәвезе, Сеңгерән, Кадер, Исәммәт, Торачы, Кыпчак, үз милләтен саткан Тәлгат Рахмановны үстергән Габдулла, Сарман районындагы Дөмәй-Тарлау авылын төп утары итеп токкан һәм 1704-1711 еллардагы милли-азатлык явының бер юлбашчысы булган, тик 1708 елда Казан кирмәне каршында кабыргасыннан асып үтерелгән Дөмәй Ишкәев хөрмәтенә аталган һәм татар милләтенә Советлар Союзы Герое Әнвәр Абдуллинны бүләк иткән Иске Дөмәй, җанисәп башланган 1719-1722 еллардан соң чукынган яңа керәшеннәр нигезләгән Андреевка һ.б. авыллар әле өченче ревизия үткәрелгән 1762-1764 елларда ук үзләрен ТАТАР дип яздырган!

Гәрчә кәнәфи колы булган һәм соңыннан күкрәкләренә орден-медаль эләктергән чинушалар 1979 елда «Илеш халкының 79 проценты башкорт!» – дип рапорт бирсә дә, асылда халыкның 85,7 проценты татар телен – туган теле дип яздыра һәм бүген дә алар газиз милләтеннән баш тартмыйча яши. Мин фәкыйрегез май уртасында ясалган сәяхәтем барышында ике тәүлек эчендә йөздән артык кеше белән әңгәмә коруга ирештем, алар арасында башкортча сыңар гына сүз дә әйтүче табылмады! Аллага шөкер, 87 авылдан хасил Илеш районындагы «Маяк» газетасының төп өлеше дә саф татарча чыга, радиоларында да гел-гел татар моңы! Инде җитәр, төп темага күчик...

Каһарман Мусаның әтисе Гайсә белән Чакмагыш районы (чиста татар!) чигендәге Имәнлекүл авылы кызы Гөлнәфисә – икесе дә «башкорт» катламына язылган була. (Фикерне бүлеп, өстәргә мәҗбүрмен: 1719 елда Петр патша бөтенрәсәй буенча халык санын алу турында карар чыгарса да, башкортлар һәм «башкорт катламы»на язылганнар арасында 1795 елга кадәр җанисәп үткәрелми. Ә җанисәпне көчләү чукындыруга әзерләү дип кабул иткән татарлар өчен «башкорт катламы»на күчү бик отышлы була. Патша хөкүмәте элек Оренбург янындагы Иләк күленнән тозны бушлай гына алган татар, башкорт, кыпчак, кыргыз-казак кебек халыкларга 1754 елдан потын 1 сум 50 тиеннән сатарга, дип карар чыгаргач, Уфа-Оренбург арасында Батырша җитәкчелегендәге зур фетнә куба, шуны бастырудан бигрәк халыкны үз ягына аудару өчен башкортлар тоз өчен акча түләүдән азат ителә. 1798 елда Уфа өязен кантоннарга бүлеп, «башкорт полклары» төзү, җайдакларны довольствиегә кую һәм ясак түләүдән азат итү башлангач та, тиз арада саны 20 гә җиткән типтәр, мишәр һәм «башкорт» полкларына бүген дә саф татар районнары булып калган Илеш, Дүртөйле, Краснокама, Бүздәк, Чакмагыш, Чишмә, Борай, Балтач, Аскын, Тәтешле, Бөре, Кушнаренко, Авыргазы, Кырмыскалы, Бакалы, Шаран, Туймазы, Ярмәкәй, Эстәрлетамак, Эстәрлебаш... кына түгел, хәтта соңрак Татарстанга күчкән Актаныш, Мөслим, Әгерже, Азнакай, Минзәлә, Әлмәт, Тукай районнарындагы авыл ирләре дә кертелә. Ә 1832 елда падишаһ указы буенча Уфа өязендә имана җирен башкортларга – 40, типтәр белән мишәрләргә – 15, татарларга фәкать 10 дисәтинә хисабыннан бүлеп бирә башлагач, татарлар инде «башкорт катламы»на корт чаккандай күчә).

Гайсә Әхмәтгәрәев саф татар авыллары булган Олы һәм Кече Бишкурайдан ике-өч чакрымда гына урнашкан Иләкшиде авылында яши. 1922 елда Гөлнәфисә аңа Муса атын алачак малай бүләк итә. Ошбу илдә тормыш көтүнең берчакта да җиңел булганы юк. 1929 елда крестьянны күмәк хуҗалыкларга куып кертү башлана. Өстәгеләр кушуы буенча, бернигә яшь гаилә Иләкшидедән 6-7 чакрымда коммуна төзергә мәҗбүр ителә. Олы Бишкурайдан 5 чакрымнар чамасы ераклыкта, тәмле чишмәсе, бик матур күле дә булган, каеннар арасына елышкан урынны сайлыйлар. Муса исә әүвәл төп өйдә калып, Иләкшидедәге башлангыч мәктәптә белем ала, аннары 7 классны Таш-Чишмә аты алган яңа авылдан йөреп тәмамлый. Кышын бураннар, язын-көзен яңгыр астында пычрак ера-ера мәктәпкә йөрү үзәгенә үткәнме, әллә төпле белем кирәклеген ныклап аңлаганмы – 1937 елда Муса Уфаның тимерьюл техникумына укырга керә, бер үк вакытта аэроклубка да йөри.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Үгисету

Ап-ак чәчле 90 яшәр ханым үз тормышын сөйли. Аның турында «әби» диясе килми. Ул - ир йөрәкле Шагыйрә. Университетларда укып, үзе тудырган хыял дөньясында очып йөргән иркә җан түгел, ә язмыш тарафыннан кагылып-сугылып, ачысын-төчесен татып, ил гамен әйтерлек булып җитлеккән шагыйрә. Ул сөйләгәннәр күз алдымда җанланып, кино картиналары кебек берәм-берәм каршымнан уза тора.

Әнә ул, биш яшьлек бәләкәй кызчык, әнкәсе белән бергә кызышып-көеп Сәпәй хастаханәсендә тифтән чирләп ята. Бер аңына килеп күзен ачканда әнкәсенең туганына васыятьләрен әйткәне колагына керә: «Балаларымны… ташламагыз…» «Әнии, үлмә!» дип кычкырганын гына хәтерли Флёра, упкынга оча. Унсигез көн кызышып, кара көеп ятканнан соң аны, инде үлде дип, подвалга төшереп куялар. Тик кызын аерып яраткан әткәсенең генә ышанасы килми, качып кына төшә дә карый, төшә дә карый. Ата күңеле сизгән икән, ул баланың култык астындагы бер тамыры тибүен шәйләп ала да, төреп, Әсәйгә алып кайтып китә. Шул көннән Флёраның ярым ятим тормышы башлана…

Үги ана бик уңган-булган, киштәсе тулы икмәк, тик бәгыренда үги кызга бер кыерчык сындырып бирерлек шәфкать табылмый… Райондагы җаваплы эшләрдә эшләгән әтисе Сабирҗан, бронь белән калу мөмкинлеге булса да, үз теләге белән фронтка китеп бара да, дүрт ел буе сугышта йөреп, 1944 елда Украина өчен барган сугышларда һәлак була. Соңгы хаты да шуннан килә: «Без атакага ташланганда кырыктан артык идек. Бу минуттан җидегә генә калдык. Монда – мәхшәр… Бөтен дөньясы ут белән чолганган. Без инде өч көн буе авызга бер тәгам ризык, су капмаган. Арыш уып кабарга да вакыт юк. Барыбыз да тереләй янып үлә барабыз», – дип язылган була анда. Әтисенең сугышта үлү хәбәрен алган 10 яшьлек бала аны бер тамчы да жәлләми: шушы кадәр усал үги ана кулына калдырып киткәнгә күңеле чамасыз әрни генә. Менә ятимә кыз капканы ачып урамга чыга, кайсы күршегә керим икән дип бермәл уйга калып тора. Кайсы йортка килеп керсә дә, какмый аны авылдашлар, «Сабирҗан абзый кызы!» – дип зурлап табынга утырталар, үз балалары белән рәттән тамагын туйдыралар.

Менә, ач-ялангачлыктан чарасыз яшүсмер кыз торф эшенә киткән апасын эзләп, авылдан чыгып китә. Тик апасы Ленинград төзелешенә киткән булып чыга, Флёра Ютазыдагы укытучысына барып егыла. Бу гаиләдә 7 ай бала карый ул. Җиде айлык, яшь тә җиде айлык ике баланы көне буе уйнатып, биетеп ардыра да, алар йоклап киткәч, китап укый. Укытучылар өендәге барлык китапны кырып-себереп укып чыга ул. Укытучы апасы матур киемнәр киендереп җибәрә аны, тик ятимлек кайтып керүгә якадан ала – авылга кайтып өй бусагасын атларга өлгерми, шул матур киемнәре белән коега төшкән чиләкне алырга җибәрәләр. Авылда багор җитмәслек тирән коеларга чумган чиләкне алырга гел ятим Флёраны төшерә торган булалар. Тик бу юлы никтер йөрәк әрни, матур киемнәр дә кызганыч, күз аткан егетенең йорты янәшәдә генә ләбаса, ул күреп алса,ояты ни бит…

Менә кыз бала күрше авылда кешеләргә җир казый. Җен урынына эшләгәнен күрше-тирәләр шаккатып карап китә. Берәүләр эшләгәне өчен бәрәңге бирә. Авыл уртасына җиткәч, бер морҗасыннан төтен чыккан йортны күреп ала да керә һәм «Минем бәрәңгемне күмеп бирмәссезме икән?» – дип сорый кыз бала. Ә анда җиде бала… Шул җиде янында ул да торып кала, кешедә җир казып йөргәндә, Җамал исемле солдат хатыны килеп, үзенә алып китә аны: «Сабирҗан абзый кызы, бүтән болай кәрәк күтәреп йөрмисең!..»

Менә Флёра унике яшеннән ат җигә башлый, «атлы молотилка»га эшкә йөри, сугылмый калган икмәк кибәннәрен чатнама кыш көннәре суктыралар. Ачсәләмә балага уку эләксә, елга бер-ике ай эләккәндер…

Менә 16 сы яңа тулган кыз баланы вербовка зәхмәте белән Кемерово шахталарына озаталар. Көненә 300 грамм ипи, бер тәлинкә тары өйрәсе бирәләр, шул ризык белән тукланып, көненә 12шәр сәгать эшлисең. Кая карама бетле чолгаулар, бетле кием кыймылдап ята. Себернең бер генә шахтасында да лифтлар эшләми, чакрым ярым тирәнлектәге су баскан шахталарга пычрак баскычлар буйлап җәяү төшәсе. Кая гына тотынма, ток суга. Флёра беренче мәтәлә-кадала төшүендә үк 48 нче үлчәмле брезент чалбарының төбе аерылып чыга, зәхмәт. Аны мастерлык вазифасын үтәүче урыс егете, лава идәненә сузып салып, сүгенә-сүгенә тимер чыбык белән ямый. Алда – 12 сәгать буе вагон этү…

Авыр эш, начар шартларга карамый, яшьлек үзенекен итә. Баракларда йөзләгән егетләр-кызлар. Флёра да бик чибәр бер егет белән танышып ала. 8 ай кулны-кулга куеп кына йөри торгач, берзаман өч көн рәттән егет килми. Гарьләнә кыз. Бик яхшы җырчы дус кызының да шул Фазыл исемле егеткә гашыйк икәнен белеп алгач, җан сөйгәнен калдырып, бу шахтадан качарга уйлый. Менә барак ишегалды тулы халык, кичке уен бара. Йөгереп түгәрәк уртасына керә дә, егермеләп егет белән бии кыз, бик шәп биюче бит ул! Йөрәгенә капкан утка чыдарлык түгел, котырып-котырып бии! Шулчак түгәрәк уртасына Фазыл сикереп төшә дә икәүләп бииләр… Ә дус кызы түгәрәк читендә елап тора… Шул төнне ап-ак күлмәген кия дә, бу шахтадан чыгып китә кыз. Кая барасын үзе дә белми.

Иртәш суын сыңар кул белән генә йөзеп чыгып, бара да бара кыз. Менә юлында бер кап-кара күл очрый. Көннәрен качып ятып, төннәрен барып ялгызлыктан шулкадәр туйган ул, күл ярына баса да кычкыра:

– Әәәй, җеннәр, чыгыгыз!

Тик бер җен дә чыкмый, 25 чакрымны 3 көндә үтеп, икенче шахтага килеп урнаша. Юлларында юньсез кешеләр дә, юньлеләре дә очрый. Юньлеләре күбрәктер шулай да. Югыйсә, буыны да ныгымаган килеш шахталарда, урман кисүләрдә, тимер юлларда 4 ел газап чиккәндә, газаплардан качып поездларда сукбайлыкта йөргәндә ул үзен хатын-кыз буларак, шагыйрә буларак саклап кала алмаган булыр иде. Шахталарда сукырайган атлар язмышы турындагы үзәк өзгеч шигырь-поэмалар да язылмыйча калыр иде… Аннары – Донбасс. Әтисенең каны түгелгән җирләрне күрә, каберенә баш ия. Хат алышкан егете Тәлгать тә 7 еллык хезмәтен тәмамлап, шунда кайтып төшә. Чибәр егет, җырчы, кызлар күңелен яндыручы. Япониянең Маньчжурия чүлен беренче булып җырлап үткән кеше. Тик озак еллар хәрбилектә эчәргә иялэшкән. Ә монда – горелка, самогон, чибәр кызлар… Уйга батса да, чыга аңа кияүгә Флёра – яратудан бигрәк, юкка чыга бит бу, дип җәлләп чыга.

Менә алар җитәкләшеп җырлый-җырлый Әсәйгә, үги ана йортына кайтып баралар. Үләргә киткән түтәкәй баеп кайта түгелме? Студебеккерга төяп кайткан чемоданнарны күрше авылдагы бер ишегалдына бушатып калдыралар да, җәяү китәләр. Бала-чага чыга каршы алырга, апалары килеп җитә. Үги анадан туган сеңелкәш исә – иң яратканы, бишектә чагыннан Флёра апасы аны үз баласы кебек күрә иң. Шахталарда эшләп тапкан акчасыннан утызлап күлмәк кенә кайтара ул аңа.

Менә Флёра гаиләсе белән Карабаш бистәсендә. Бер-бер артлы өч бала туа. Матур хатыннар белән күңел ачарга яратучы иргә ышанып торырлык түгел, тормышны алып барырга кирәк. Алып бара Флёра – көн-төн тегүдә ул. Себердә яшүсмер килеш шахта эшенең газапларына чыдый алмыйча качып шәһәрләр буйлап сукбайлыкта йөргәндә, яхшы кешеләр ятим баланы җәлләп һөнәр училищесына урнаштыра, шунда өйрәнгән тегүче һөнәренең кирәге

● Флёра Гыйззәтуллина, Минтимер Шәймиев. 2011 ел.

● Флёра Гыйззәтуллина, Гөлзадә Сафиуллина, Гөлшат Зәйнашева. 1990 ел.

чыга! Карабаштагы ательеда 12 авылга тегү тегә, унлап мохтаҗ гаилә хатын-кызларын бушка тегү эшенә өйрәтә. Ирләр нефть эшендә, ә хатын-кызларга эш юк. Үзе кисә, үзе тегә, исәп-хисабын да алып бара. Кичке мәктәптә дә укый.

Эштә ут уйнаткан, гаилә йөген тарткан ханымның күңелендә исә шигырь яши. Үзе турында шагыйрә дип уйламый да ул, тик күңел дигәнең гел шигырьгә, иҗатка, язучыларга тартыла. Гариф Ахунов, Шамил Бикчурин, Сажидә Сөләймановаларның үзләренә генә түгел, бөтен гаиләләренә ярдәм итеп, тегеп киендереп яши ул. Ә ярдәм итәргә хәленнән килә, бер тәүлеккә әллә ничәшәр туй күлмәге тегеп, күз нурларын түгеп аякка баса ул. Кырык эше арасыннан Рафаэль Мостафин белән 7 ел хат алышырга вакыт таба ала. Муса белән бергә тоткынлыкта булып, туган илгә кайткач төрмәгә ябып юк ителгән кешенең эзләрен барлап, әйберләрен бөртекләп җыя, табылган бер шигырен, Алишның дәфтәрләрен Рафаэльгә җибәрә тора. Менә шул Мостафин хатлары аны тормыш баткаклыкларыннан исән алып чыга да инде. Югыйсә, фаҗиганең иң ачысы – бала хәсрәте белән дә сыный язмыш дигәннәре. Язучыларга ихластан игелек кылып яшәсә дә, дәфтәр калынлыгы гына шигырь китабын да бөтен көенчә түгел, әллә ничә җыентыкка бүлгәләп бетерәләр. «Эх, Казанга күчәсе, әдәбият казанында кайнап яшисе иде», – дигән якты уй ничә еллар инде кушеккән күңелне җылытып тора да бит… Тик аңа кадәр әле Тольяттига күчеп, бу шәһәрне нигезеннән башлап салышасы, анда фатир алып, ул фатирны Казандагы белән алыштыру өчен 8-9 ел көтәсе бар. Йөзләгән шигырьләр китап булып басылмыйча, ничә еллар укучысына барып җитә алмый яши. Ниһаять, 1980 елда күңеле тулы җирсү, иҗатка сусау, тормыш алып бару өчен сарыф ителгән еллар багажы белән Флёра ханым Гыйззәтуллина Казанга кайтып төпләнә. Аллаһы Тәгаләдән йөкләмә итеп бирелгән талантын тормышының иң катлаулы чорларында да юкка чыгармыйча саклап, ул дистәләгән поэмалар, шигырьләр, җырлар иҗат итте. Үз язмышын хурламыйча, гыйбрәт итеп, ватан гаме белән сугарылып, ул кайбер язучы исеме күтәреп йөргән үгез кебек ирләрнең төшләренә дә кермәгән әсәрләр язды. Иң авыр жанрларның берсе булган поэма жанрын иярләде, җан тетрәп укырлык йөзләгән әсәр иҗат итте. Дистәдән артык китабы басылып чыкты. Китаплары укучылар тарафыннан «Ел китабы» бәйгеләрендә җиңү яулады. Бүген 90 яшен тутырган хәлдә дә каләмен ташламый ул.

«Күрәсезме? Мин бүген дә язам!
Телләремне, билләремне язам…
«Күп яздың!» – дип битәрләмә, Казан!..
Язу – минем теләп алган җәзам», –

дигән Шагыйрәгә ашкынып кайткан башкаласы гына әлегәчә тиешле бәясен бирә, аның зур иҗатын тиешенчә бәяли белмәде. Төрле китаплары өчен сигез тапкыр (!) Тукай бүләгенә кандидат итеп күрсәтелеп тә, әлегә кадәр шул мөкатдәс бүләкнең аңа тапшырылмавын ничек аңлатырга?

… Яшь бөртеге исәбеннән саный китсәң,
Мин Тукайның күп гасырлык
сеңелкәше!
Әмма исрафлыкта узган ул вакытны
Нинди назлар түгеп кабат терелтәсең?!
Ни әйтсәң – тук чырайлы әзмәвергә –
Үзен: «Тукай токымы!!!» –
дип таныткaнда.

● Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия тапшыру тантанасында. Әлмәт. Октябрь, 2006 ел.

Борчак бөртегедәй ымсындыргыч
Өметеңә синең каныкканда?!

– дигән юллары күңелне сискәндерә, Ватан гаме белән иҗат иткән ак чәчле шагыйрә алдында оялудан, гамьсезлегебез, ваемсызлыгыбыз өчен уңайсызланудан җан бөрешә.

Тауларым да, таңнарым да минем
Мәхәббәткә ядкәр булып кала.
Сөю бүләк иткән чулпыларым
Үрелеп кала гасыр толымында.
Юк, мин дусны түгел, дошманны да
Аунатмадым тарих корымында.
Җанда Аккош күле яралганда
Мин гүзәллек иҗат иттем бары –
Илнең киләчәген сафландырып
Агымсулар аксын өчен ары…
Бүген дә мин Арча парчасыннан
Туй күлмәге җөйлим – йөзәрләгән…
Шуңа карамастан милләтемнең
Җан ярасы әле төзәлмәгән… –

дип йөзләрчә халыкчан, образлы, коеп куйган гүзәл телле, корыч рухлы әсәрләре белән Шагыйрә халкыбыз күңелендә күптән үзенә үзе һәйкәл куйды инде. Тик без генә моны танып, үгисетүдән туктап, аны зурлап өлгерербезме, белмим. Фатихасыз калмасак иде.

Эльмира СИРАҖИ.

Атнаның сәяси мизгелләре

КОМБИНАТ ФАҖИГАСЕ

Россиянең оборона министры С.Шойгу 20 майда РФ президенты В.Путинга Мариупольнең тулысынча азат ителүе, «Азовсталь» металлургия комбинатында җир асты корылмалары Россия гаскәрләре контроленә күчүе турында хәбәр итте. Анда 21 апрельдә «чебен дә очып үтмәслек итеп» ябылган Украина хәрбиләре вә «Азов» батальонынннан, 16 майдан соң җәмгысе 2439 «боевик», корал ташлап, Россия көчләренә бирелүе турында белдерде. Соңгы көннәрдә бу хакта Россия мәгълүмат чараларында инде кат-кат сөйләнде һәм җимерелгән кала белән «Азовсталь» хәрабәләре дә күрсәтелде. Соңгысын бөтенләй юк итү турындагы тәкъдимнәр дә булды. Шуның белән бергә, Женева конвенциясенә туры китереп, әсир төшкәннәргә – гуманлы мөнәсәбәт, яралыларга исә медицина ярдәме күрсәтелүе турында да әйтелде. Бу җәһәттән, инде аңлашыла булыр, әсир төшкәннәрнең киләчәге хакындагы четерекле мәсьәлә дә алгы планга чыкты.

Украина президенты В.Зеленский сүзләренә караганда, «Азовсталь» сугышчылары әлеге адымга Киев рөхсәте белән барган. Ул аларны әсир төшкән Россия сугышчыларына алыштырып алуга исәп тотуы турында әйтә, барысы да Россиянең, шулай ук «Кызыл Хач» оешмасы һәм БМОның үз сүзләрендә тора алу-алмавына бәйле булуы хакында да искәртә. Әмма каршы яктан аларны хәрби трибунал хөкеменә тарту, яисә җимерелгән Донбассны торгызуда куллану таләпләре дә ишетелгәләде. Киев исә Россия-Украина сөйләшүләренең киләчәген дә «Азовсталь» сугышчылары язмышы белән бәйләп карый икән. Кыскасы, әлегә «Азовсталь»нең киләчәге генә түгел, әсир төшкән сугышчыларның язмышлары да билгесез булып кала. Әмма хәлләр гел үк өметсез дә түгел кебек. Һәрхәлдә, РФ Дәүләт Думасында бериш депутатларның әсир төшкән «Азов» батальоны сугышчыларын алыштырып алуны тыю турындагы карар проекты көн тәртибенә кертелмәгән.

Атнаның башка вакыйгалары да, асылда, Украинадагы хәлләр белән бәйле булды. Әйтик, Финляндия һәм Швеция НАТОга керү турында бер үк көнне гариза бирделәр. Альянста бу мәсьәләне, тизләтелгән режимда, бернәчә ай эчендә хәл итәргә җыеналар. Украинаның Европа Берлегенә әгъза итеп алынуы да озак көттермәс кебек. Һәрхәлдә, Европа комиссиясе башлыгы Урсула фон дер Ляйен сүзләренә караганда, барысы да аның үзеннән тора. Гадәттә, моның өчен бернічә ел кирәк була икән. Украина икътисады никадәр тизрәк торгызылса һәм реформалар үткәрелсә (ә Европа бу эшләрдә аңа ярдәм итәргә җыена), ул шулай тиз анда әгъза итеп тә алыначак. АКШ президенты исә Украинага 40 миллиард доллар күләмендә өстәмә ярдәм турындагы законны да имзалаган. Ә Мәскәүнең – үз исәпләре. Херсон өлкәсендә референдум үткәрү нияте дә үзен сиздерә. Кырым башлыгы С.Аксенов Херсон һәм Запорожье өлкәләре Кырым белән бер үк илдә булачагын әйтә. Охшаш фикерләрне РФ вице-премьеры М.Хөснуллин да ишеттерде.

Фоат УРАЗАЙ.

Режиссерның гомер бәйрәме



Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, артист, педагог, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм Д.Сираҗиев премиясе лауреаты Фәрит Бикчәнтәев 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Режиссер үзенең гомер бәйрәмен бик үзенчәлекле уздырды. Ул үзен сәгатьләр буе сәхнәдә утырып торудан коткарып, юбилее көнендә күренекле язучы Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары буенча куелган «Ирдәүкә. Мөһаҗирләр» спектакленең генераль прогонын тәкъдим итте. Ф.Бикчәнтәев бәйрәмен театрны тутырып килгән тамашачы алдында залда утырган әнисен – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Наилә Гәрәеваны хөрмәт итүдән башлады. «Бу залда минем әнием утыра. Ул – татар театрының легендасы! Бүген – аның көне!», – диде ул. Дөрестән дә, Наилә ханым, фойеда үзара аралашып алганда искәрткәнчә, бу – аның иң бәхетле көннәренең берсе. «Улыма әтисе Рәфкать Бикчәнтәевнең табигатьтән бирелгән таланты күчкән, ул аның дәвамчысы булып яши, аеруча шул бик шатландыра. Аннары, Аллаһыга шөкер, баланың шушы яшькә җитүен күрү дә – зур бәхет. Фәрит һәр җирдә дә үзе булып, театрга тугрылыклыгын саклап кала алды. Минем өчен бу да – кешедәге асыл сыйфатларның берсе», – диде ул.

«Монда минем дусларым, туганнарым, безнең театрыбызны яраткан тамашачым утыра. Менә мин шундый формат сайладым. Мин күп кешеләрне сәхнәгә чыгудан коткардым. Сәхнә – ул артистныкы, режиссерның урыны – кулиса артында», – диде юбиляр.

Әлбәттә, Фәрит Бикчәнтәевнең озак еллар татарның олуг театрына баш режиссер буларак та хезмәт итүе чорында халкына сөйләрдәй уңышлары байтак иде. Әйтик, ул үтә нечкә психологиягә корылган «Хушыгыз!» (Т.Миңнуллин) спектакле өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. Ул куйган «Көз» (Г.Исхакый, инсценировка авторы – И.Мөхәммәтгалиев), тирән фәлсәфәгә корылган «Җирән чичән һәм Карачәч сылу» (Н.Исәнбәт) спектакльләренең «Нәүрүз» Халыкара төрки халыклар театр фестивалендә (1998, 2002) «Иң яхшы режиссура эше өчен» номинациясендә җиңүче, «Кара чикмән» (Г.Хугаев) спектакле өчен Гран-прига ия булуын, «Алтын битлек» театраль премиясе номинанты икәнлеген хәтерлибез.

Танылган драматург Илгиз Зәйниев тә, үзара сөйләшеп алганда, Ф.Бикчәнтәевнең әсәрне куярга алынуы, драматург өчен зур бәхет икәнлеген белдерде. «Чөнки ул әсәрне автор язганнан да тирәнрәк итеп эшләп, сәхнәгә чыгарачагын беләсең», – диде ул.

Юбилей көнендә тәкъдим ителгән «Ирдәүкә. Мөһаҗирләр» спектаклен дә өч пәрдәле итү ниятләнгән. Татар халкының авыр язмышын чагылдырган, һәм чын вакыйгаларга нигезләнеп иҗат ителгән спектакльне (инсценировка авторлары – И.Мөхәммәтгалиев, И.Зәйниев, рәссамы С.Скоморохов, хореограф Н.Батулла, композиторы Е.Шилова), ике сәгатьтән артык баруына карамастан, тамашачы тын да алмый карады. Спектакльнең төп премьерасы исә көз көне – традиция буенча Марсель Сәлимҗанов туган көнендә куелачак.

Бу көнне спектакль алдыннан театр фойесында Фәрит Бикчәнтәевнең иҗатына багышлап рус телендә язылган китап та тәкъдим ителде. Авторлар аның алга таба татарчасы да нәшер ителәчәген әйтте. Басманы башта ике телдә дә чыгару турында уйланган булган. Әмма китап шактый саллы – 600 битле килеп чыгу сәбәпле, ул әлегә бер генә телдә дөнья күргән. Хезмәтнең авторы – танылган театр белгече, «Петербургский театральный критик» журналының баш мөхәррире Марина Дмитревская. Ул китапны Камал театрының әдәби-драма бүлеге мөдире Гөлшат Фәттахова белән бергәләп эшләгәнен әйтте. Г.Фәттахова бик зур репетиция барышын яздырып аңа расшифровка ясаган. Ул «Сүнгән йолдызлар» спектакленең «өстәл чорын»нан башлап, премьерага кадәр күрсәтә алды», – дип китап әзерләү барышы белән таныштырды М.Дмитревская. Театр белгече, гыйнвар аенда Казанга килеп, Фәрит Бикчәнтәев белән атна буе әңгәмә корган. «Мин үз гомеремдә моннан да озын интервьюның булганын хәтерләмим», – диде Марина Дмитревская. Күренекле театр эшлеклесе, тәнкыйтьче Олег Лоевский Фәрит Бикчәнтәевне талантлы режиссер, олуг педагог, милли мәдәният һәм туган теле сагында торучы шәхес буларак сурәтләде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Фото: Kamalteatr.ru.

Җир кешесе

Язучы, шагыйрь, галим, танылган бакчачы Фарсель Зыятдинов бик актив кеше иде. Ул көн дәвамында төрле урыннарда булырга, бик күп кешеләр белән очрашырга, мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә өлгереп яшәде. Фарсель – чын мәгънәсендә җир кешесе иде. Гомере буе мул уңыш үстерүнең серләрен өйрәнде, аны башкаларга да өйрәтте.

Фарсель Сәхап улы – беренче президентыбыз Минтимер Шәймиевнең якташы, Актаныш районыннан. 1937 елның 1 июнендә Качкын авылында туган. Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Тәтештә, агрономнар техникумында укый. Техникумны тәмамлагач, бераз эшләп ала да, укуын дәвам итә. Бу юлы инде берьюлы ике урында – Казан дәүләт университетында һәм М.Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтында. Берничә ел укыгач, Татарстан радиосына хәбәрче булып эшкә урнаша. Укуы белән беррәттән даими рәвештә тапшырулар әзерли.

Ф.Зыятдинов күпчелек имтиханнарын башка студентлардан алдарак тапшыра. Нәтиҗәдә 1965 елда университет, 1966 елда авыл хуҗалыгы институты дипломнарын алып чыга. 1964-1970 елларда радиокомитетта эшли. Шушы чордан башлап озак еллар дәвамында Казан телевидение студиясендә ай саен авыл хуҗалыгының актуаль проблемаларына багышланган тапшырулар да әзерләп алып барды.

Фарсельнең кыска вакыт эчендә бик актив иҗат кешесе булып формалашуына аның университетта бик талантлы егетләр һәм кызлар белән бер группада укуы да зур йогынты ясагандыр дип уйлыйм. Бу төркем Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов кебек ул вакытта ук республика күләмендә танылган язучылардан, Рүзәл Юсупов кебек беренче курстан ук фән дөньясына кереп чумган шәхесләрдән тупланган иде. Аларның күпчелеге укыган чорда ук китаплар чыгарды, укуны тәмамлауга диссертацияләр яклады. Фарсель дә 1975 елда кандидатлык, 2002 елда докторлык диссертациясен яклый. Актив каләм иясе буларак, язучылар һәм журналистлар берлекләренә кабул ителә.

1970-1986 елларда Ф.Зыятдинов Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институтында бүлек мөдире булып эшләде. Бер үк вакытта Казан университетында студентларга лекцияләр укыды, семинар дәресләре алып барды. 1986 елдан Казан финанс-икътисад институтында укытты, 2004 елдан шунда ук икътисад кафедрасы профессоры вазифасын башкарды. Төп эшеннән аерылмыйча, бераз вакыт педагогика һәм энергетика институтларында эшләп алды.

Фарсельнең әдәби әсәрләре 1960 елда ук басыла башлый. Бу елда аның балалар өчен шигырьләр һәм хикәяләр җыентыгы чыга. 1974 елда балаларга багышланган “Кызык дөнья”, 1983 елда “Гыйлем белән белем”, 1988 елда “Онытылмас авазлар”, 2000 елда “Икътисад әлифбасы” китаплары дөнья күрә.

Ф.Зыятдиновның күпләр яратып укый торган лирик шигырьләре дә аз түгел. 1991 елда чыккан “Тагын килде язлар” китабына тупланган шигырьләре һәркемне сокландырырлык. Авторның 1975 елда чыккан “Кырлар батыры” китабына документаль повестьлар һәм хикәяләр тупланган. 1997 елда селекционер галимнәргә багышланган “Изге йорт” повесте дөнья күрә. Тагын бер елдан Фарсельнең якын дусты, педагогика институты ректоры, академик Рүзәл Юсуповның тормыш юлына багышланган “Яшәү мәгънәсе” китабы чыга.

Бу мәкаләне язар алдыннан гасырлар чигендәге “Татарстан” журналының кайбер саннарын карап утырдым. Аларда Фарсельнең берничә язмасы бар иде. Барысы да җирне кадерләү, саклык белән куллануга багышланган. Бер мисал китереп үтик. “Җир – ул төп яшәү чыганагы. Бер үк вакытта җитештерү чарасы да, хезмәт кую урыны да. Менә шуңа күрә җирне без төп җитештерү чыганагы дип атыйбыз. Аны күчереп тә, алыштырып та булмый. Белеп эш иткәндә ул тузмый, уңдырышлылыгын арттыра бара, байлык тудыра. Тик аны авыл хуҗалыгы максатларында файдаланганда гына бу шулай. Әгәр дә без җирне башка максатларда, әйтик, сәнәгать предприятиеләре, төрле складлар, коттеджлар төзү өчен файдалансак, ә инде файдасыз электр станцияләре корып, җирне су астында калдырсак, ул җитештерү чыганагы булудан туктый, өстәмә байлык тудырмый”. (“Татарстан”, №7, 2001).

“Россиядә җирдән күп нәрсә юк. Ә шулай да гасырлар буе халыкның тамагы туйганы булмады. Безгә һич тә Россиягә иярергә ярамый. Анда файдаланылмый калган җирләрнең исәбе-хисабы юк. Гомумән, статистика соңгы йөз елда Россиядә муллык булганын расламый. Моның төп сәбәпләреннән берсе – җирнең хезмәт сөючән, төпле хуҗасы булмауда. Ул инкыйлабка кадәр дә шулай иде, аннан соң да шундый ук хәл. Бу исә халыкның тарихы, гореф-гадәтләре белән бәйле булса кирәк. Яңа җирләргә кул сузып һәм чит мәмләкәт җирләрен яулап алып гомер кичергән халык искеләрен яңарту, аларны уңдырышлы итү турында уйламаган, моңа гадәтләнмәгән. Еш кабатлана һәм һәрвакыт эчү белән тәмамлана торган бәйрәмнәр дә кыр эшләрен үз вакытында үткәрергә комачаулаган. Өстәвенә җирдә эшләүчеләрнең хезмәт активлыгы түбән. Соңгы алтмыш-алтмыш биш ел эчендә формалашкан хуҗасызлык, ягъни “гомумхалык милке”, “уртак милек” хезмәт дәртен тагын да киметте” (“Татарстан”, № 4, 1998 ел).

Фарсельнең фәнни китаплары, монографияләре дә күп. Аларның барысы да авыл хуҗалыгына, беренче чиратта җир эшкәртүгә багышланган. Ф.Зыятдинов республикада бакчачы галим буларак та танылды. Аның “Ямь һәм тәм, яки Безнең бакча” дип исемләнгән китабы халык арасында бигрәк тә популяр. Күрәсең, җирнең серләрен яхшы белүе, дачасындагы җир кишәрлегендә дә сынаулар үткәрүе роль уйнагандыр.

Татарстан – тотрыксыз авыл хуҗалыгы зонасына урнашкан төбәк. Бездә һәр елны даими мул уңыш үстерү бик авыр. Бу хакта президентыбыз Р.Миңнехановның Татарстан парламентына еллык юлламасында да әйтелә. Ул 2021 елда корылык булуын искәртте.

Икътисад фәннәре докторы, профессор, язучы Фарсель Зыятдиновның хезмәтләре югары бәяләнде. Аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, республиканың атказанган фән эшлеклесе мактаулы исемнәре бирелде. Ул СССР бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең көмеш медале, Татарстан Республикасының мактау грамотасы белән бүләкләнде. 2021 елның 16 августында Фарсель Сәхәп улы безнең арадан бакыйлыкка күчте. Ул чын мәгънәсендә җир кешесе иде. Җир дә аны җылытмый калмас.

Әгъзам
ФӘЙЗРАХМАНОВ.

ЮЛГА ЧЫККАНДА

– Үстеләр канатлар,
Әнкәем мин китәм...
– Кайларга китсәң дә,
Кайт, улым, мин көтәм!..
Мин киттем.
Әнием озата чыкканда,
Каеннар уянды шыбырдап.
Оясын югалткан кош кебек
Тәнкәем куйды, әй, чымырдап.
Әнием күңеле шикелле,
Каеннар шыбырдый җай гына:
«Китмә син, әй, улым, кал инде,
Кал инде бер көнгә, аз гына...»
Еракка-еракка юл буе
Озата бардылар арышлар.
Тоямын: башаклар шавында
Шундый ук бер моң бар, сагыш бар.
Әнием күңеле шикелле,
Башаклар пышылдый тын гына:
«Китмә син, кал инде, әй, улым,
Кал инде бер көнгә, аз гына...»
Башаклар пышылдый тын гына...

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

28 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 2.28 сәгатьтә калка, 17.57 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.59 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Юкә балы

Озакка сузылган ютәл, пневмония, туберкулездан болай дәваланып була. 150 г каен бөресе, 50 г юкә чәчәген ярты литр суда 10 минут кайнаталар, бераз суытып, сөзәләр. 1 кг юкә балына 200 г ваклап туралган алоэ яфрагы, каен бөресе белән юкә чәчәге төнәтмәсе, 200 г зәйтүн мае кушып яхшылап болгаталар. Көненә 3 тапкыр 1 әр аш кашыгы кабалар, кулланыр алдыннан әйбәтләп болгаталар.

29 май (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 2.39 сәгатьтә калка, 19.17 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.02 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Паркинсон чиреннән дәва

Паркинсон авырулы кешенең куллары калтыравын болай киметеп була. 9 аш кашыгы солыны 3 литр суда сүрән утта 1 сәгать буе пешерәләр. Яхшылап төреп, җылы урында 8 сәгать төнәтәләр. Сөзеп, көн дәвамында эчеп бетерәләр. Дәва курсы – кимендә 6 ай. Яисә 1 аш кашыгы кычыткан яфрагын 200 мл кайнар суда 1 сәгать төнәтәләр, сөзәләр. Ашарга ярты сәгать кала чирегешәр стакан эчеп, көн буена эчеп бетерәләр.

30 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 2.54 сәгатьтә калка, 20.34 сәгатьтә бата. 14 сәгать 30 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 17.04 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Бүген авырый башлаган кеше озак чирләячәк. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Тамырларны чистарту

Ай Игезәкләрдә чакта кан тамырларын чистарту яхшы нәтиҗә бирә. Соңгы фәнни тикшеренүләр күрсәткәнчә, баш авыртуы баш мие зарарланудан түгел, ә 90 процент очракта кан тамырлары авыруы аркасында килеп чыга. Йөрәк чирләренең сәбәбе исә – канда холестерин арту. Аның микъдарын

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

киметү өчен, зәйтүн мае, кузгалак, яшелчә һәм җиләк-җимешне күбрәк кулланырга кирәк. Авырлык нормадан артмасын. Көн саен бер генә бүлем булса да сарымсак ашау инфарктган да, яман шештән дә саклар.

31 май (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 3.15 сәгатьтә калка, 21.46 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы17.07 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

1 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,3.47 сәгатьтә калка, 22.45 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.09 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Сөтле солы

Кәстрүлнең өчтән ике өлешенә солы яки арпа салып, сөт белән тутыралар, капкачын ябып, җылы газ миченә куялар. Солы пешеп чыкканчы тоталар, сөт өсти баралар. Каты ютәлне басу өчен, көненә 3 тапкыр 2-3әр аш кашыгы кабалар.

2 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,4.32 сәгатьтә калка, 23.30 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.11 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Теш сызлаганда

Яртышар чәй кашыгы сода һәм тозны 1 стакан кайнаган суга салып болгаталар да, бераз суынгач, әледән-әле авызны чайкыйлар. Яки суганның согын сыгып, теш щеткасын шунда чылаталар да, сызлаган теш янындагы уртка ышкыйлар, көненә берничә тапкыр кабатлыйлар. Авызны чөгендер согы белән чайкау яки чөгендер телемен озаклап чәйнәү дә сызлауны баса.

3 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 5.32 сәгатьтә калка, 0.01 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.14 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланую күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Сәдәф-печенье

40 данә печеньега: 100 г атланмай, 1 аш кашыгы ванильле шикәр, 4 аш кашыгы шикәр, 2 йомырка сарысы, 200 г он кирәк. Камыр басып, 1 сәгатькә суыткычка куялар. Пергамент кәгазе өстендә җәеп, диаметры 5 сантиметрлы түгәрәкләр кисәләр, кечерәк шешә капкачы белән эз төшерәләр, коктейль көпшәсе белән 4 тишек тишәләр. Кәгазьне майлы табага күчереп, 180 градуслы газ мичендә 10-12 минут пешерәләр.

Халык фикерен сорап тормыйлар

Телебезгә карата биш гасыр буе барган һөҗүмнең хәзергә кадәр тукталып торганы юк.

Туксанынчы елларда башланып киткән үзгәрешләр нәтиҗәсе буларак, республиканың бәйсезлеге турында декларация кабул ителгәннән соң тудырылган мөмкинчелекләрдән файдаланасы урында, милли җанлы депутатларыбыз чыгышларында әйтелгән тәкъдимнәрнең үз җитәкчелегебез тарафыннан кабул ителмәве зур ялгышлык булды. Кемнәргәдер ярарга тырышып та, ярый алмаганнары өчен, үкенә дә торганнардыр, бәлки.

Ул елларда, Дәүләт Советы депутатларының ясаган чыгышлары тулысы белән телевизорда күрсәтелә иде. Ул вакытта сайланган халык вәкилләре арасында хәрәмләшүсез, гаделлек белән сайланганнары бар иде. Милли җанлы депутатларыбыз да, шовинистик карашлылары да күп иде. Соңга таба сайлауларда андыйларны үткәрмәделәр. Үз телендә чыгыш ясый торган, милли җанлы 1-2 генә депутат калдырылды. Милли җанлы депутатларыбыз күбрәк булганда, миллилек хокукларыбызны яклау өчен, җитәкчелекнең үзенә дә җиңелрәк буласы бит югыйсә.

Фәндәс ага Сафиуллинның тырышлыгы нәтиҗәсе буларак, милли университет ачу турында карар кабул ителгән иде бит. Ни кызганыч, милли университет ачу түгел, әлегә кадәр булганын да бетереп, милли мәгариф укыту системасы өчен кадрлар әзерли торган педагогика институтын юкка чыгарып, федераль университетка кушып куюлары да, үзебезнең җитәкчелек тарафыннан башкарылды түгелме? Аның белән генә дә тукталып калмыйча, балалар бакчаларыннан башлап, мәктәпләрдә ана телендә укуларны тыюга багышланган законны Дәүләт Советы депутатлары бер тавыштан яклап чыктылар. Бик сәер күренеш түгелме бу? Ничек кенә әле. Бу сәерлекне, югарыдан төшерелгән әмер буенча башкарылганлыгын белсәк тә, каршылык күрсәтеп, халык фикерен сорау булмады.

Төп законда бирелгән миллилек хокукларыбызның үтәлешен таләп итүче 80-86 яшьлек бабайлар экстремистлыкта гаепләнеп, штрафлар түләп суд юлында йөрергә мәҗбүр ителәләр. Бәйсезлек турында декларация кабул итүдә иң зур өлеш кертүчеләр иде бит алар. Аларның да күбесе, үзебезнең җитәкчелек тарафыннан кадер-хөрмәт күрмичә китеп бара. Хакимият югарылыгында аларны искә алу очрагы булмаса да, аларны халык белә, алар милләт каһарманнары булдылар. Илдус Садыйков та (урыны җәннәттә булсын,) машина алырга дип җыйган акчасын тотып, Америкага барып, референдум үткәргәндә катнашу өчен халыкара экспертлар алып килеп, референдум нәтиҗәләрен тулы хокуклы итеп башкарган өчен дә рәхмәт әйтүче булмады.

Наданлыкка өндәү була түгелме?

Татарстан халык шагыйре Ренат Харисның: “Укытучы – кеше җанының баш инженеры” дигән мәкаләсендә (“Мәдәни җомга”, 29.04.2022 ел, №16) язылган кайбер фикерләре сәер күренде. Безгә ана телебезне, беренче нәүбәттә, кухня теле, базар теле, урам теле буларак, ягъни халык теле, аның уй-фикер йөртү, эш итү теле буларак саклап калу кирәклеге турында әйтеп, бер шигырендә язылган, “Кухня теле кадерлерәк парламентлар теленнән” дигән сүзләре аптырашта калдырды. Шул очракта гына телебез парламент теле, фән теле, әдәбият теле, җыр теле булачак, – дигән автор. Татарстанның халык шагыйре, үзе дә республика парламентында депутат булып торган кешедән, мондый сүзләр ишетү сәер. Бу наданлыкка өндәү кебек күренде. Кухня, урам, базар телләре белән парламентта чыгыш ясап буламы? Бу телләрне фәндә, әдәбиятта, җырларда кулланып, әдәби телдә китап, шигырьләр язып булыр микән?

Безнең милли университет, институтларыбыз эшләмәсә, кухня, базар, урам телләре белән калган нәүбәттә, язучы, шагыйрь, тел белгечләре, галимнәр, артистларыбыз, милли җанлы җитәкчеләребез булмаса, ул вакытта без кем булабыз, Ренат әфәнде?

Казан федераль университетында күп фәннәр буенча көчле белгечләр әзерләнүе турында язса да, татар теле белгечләре әзерләүнең мөшкел хәлдә булуы, Ренат әфәндене борчымый кебек күренде.

Хөрмәтле академигыбыз Рүзәл Юсупов Казан педагогика университетын бетерүне зур фаҗига, хәтта җинаятькә якын гамәл дип санавын искә алып, соңгы ярты гасырда татар халкының, Татарстан дәүләтенең, милли культурасының иң зур казанышы итеп татар энциклопедия институты чыгарган китапларны атый хөрмәтле шагыйрь. Педагогика университетының бетерелүе зур югалту, аны торгызырга кирәк дип әйтсә дә, илебезгә, республикабызга кирәкле барлык һөнәр ияләре, белгечләр үзебездә дә, Россиянең башка югары уку йортларында да, хәтта чит илләрдә дә әзерләнә, дип тәмамлый автор үз мәкаләсен. Кайлардадыр, нинди һөнәр ияләре әзерләүгә караганда, мәктәптә балаларга үз ана телендә укулар тыелуы күбрәк борчый безне, Ренат әфәнде. Телебезне саклауның юлы бер генә, мәктәпләрдә ана телендәге укулар элеккеге форматка кайтарылып, кайбер югары уку йортларында дәвам ителгәндә генә, телебезнең сакланып калуына өметләнергә була.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.
Казан.

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

27 май – зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров). Кече залда – «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).
28 май – Шәрык клубында 14.00 – «Гөлҗамал. Чакыру» (Н.Исәнбәт). 18.00 – «Исәнмесез!?.» (М.Гыйләҗев).
29 май – Шәрык клубында 14.00 – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). 18.00 – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
31 май – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
1 июнь – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
2,3 июнь – Евгений Вахтангов исемендәге академия театрының «Война и мир» спектакле (Л.Толстой).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

28 май – «Баядерка» (Л.Минкус).
30-31 май – Р.Нуриев исемендәге XXXI халыкара классик балет фестиваленең гала-концертлары.

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

27 май – «Полиционер» (И.Зәйниев).
29 май – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
30 май – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
31 май – 13.00, 15.00 – «Менә сиңа куш кулым» (А.Садриев). 18.30 – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
1 июнь – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
2 июнь – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).
3 июнь – «Беренче театр» (Г.Камал).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

27 май – Премьера. «Тимур һәм комета» (П.Коротыч).
31 май – «Озын-озак балачак» (М.Кәрим).
1 июнь – 13.00 «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.30 – «СалаваTik» төркеме концерты.
2 июнь – «Нигез ташлары» (Т.Миңнуллин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

27 май – 11.00, 13.00 – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Распе). 19.00 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
28 май – 11.00, 13.00, 15.00 – «Малыш и Карлсон» (А.Линдгрен), 12.00 – «Мактанчык әтәч» (Аманулла).
29 май – 10.00 – «Тыпырдык» (И.Зәйниев). 11.30, 12.30 – «Идет коза рогатая» (М.Протасова). 12.00, 14.00 – «Цветик-семицветик» (В.Катаев).
31 май – «Misterioso con anima» (Е.Ибраһимов).
3 июнь – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

27 май – Татарстанның халык артисты Зәйнәб Фәрхетдинова концерты.
28 май – Җырчы Илгәрәй концерты.
30 май – «Татар сүзе» бәйгесенең гала-концерты.
31 май – «Су тавышы һәм тынлык гармониясе» дип исемләнгән лекция.
2 июнь – «Сурганова һәм Оркестр» төркеме концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

27 май – «La Primavera» оркестрының XXXII иҗат фасылын ябу концерты.
30 май – Татарстан һәм Россиянең халык артисты композитор Рәшит Кәлимуллинның иҗат әсәрләреннән концерт.
31 май – «Бахтан Яхинга кадәр» дип исемләнгән орган концерты. Органда Фәридә Нуруллоева уйный.
2 июнь – Бәрмә музыка уен коралларында уйнаучыларның «Ритмомания» дип исемләнгән концерты.

Утта янмас хан кызы, яки «Кара пулат»ның яңаруы

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Кара пулат» операсы кабат сәхнәгә кайтты. Ул 2015 елда республикабызның Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фонды ярдәме белән сәхнәләштерелгән иде.

Болгарда ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлап аны кабат торгыздылар. Композитор Эльмир Низамовның шагыйрь Ренат Харис либреттосына иҗат ителгән, режиссер Георгий Ковтун сәхнәләштергән опера борынгы чорлардан бүгенге көнгә килеп җиткән утта янмый торган хан кызы турындагы риваятькә нигезләнгән, Аксак Тимернең Болгарга яу белән килгән чорны үз эченә ала.

Элекке куелыш белән чагыштырганда, театрның оркестры зурайганы күзгә ташлана. Дирижер Ильяс Камал үз тирәсенә үзе кебек яшь, талантлы музыкантларны туплап, көчле коллектив җыюга ирешкән.

Спектакльдә хан кызы түшендәге күзләрне камаштырып ялтыраган энҗе-мәрҗәннәр дә, Кара пулатка видеопроекция ярдәмендә төшерелгән шәрыкчә нәфис бизәкләр дә, болгарларның илбасарларга каршы үзләрен аямыйча сугышуы да, Аксак Тимер токымының гаярьлеге, кызларның туган ил дип өзгәләнүе дә күңелгә рәхәтлек бирде. Чичән-шагыйрь ролендә чыгыш ясаган Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисов үзенең матур тембрлы тавышы, камил яңгырашлы татлы сөйләме ярдәмендә сәхнәдәге вакыйгаларга җылылык өстәде, хәтта татар тамашачысына бик үк якын булмаган опера жанры да газиз булып куйды.

Дөрес, спектакль кимчелекләрдән хали түгел. Тамашаның либреттосы ук байтак сораулар тудыра. Автор илне дошманнан саклаучыларга дан җырлау максатын куйган икән, нигә, мәсәлән, Биләрне саклап һәлак булган кырык кыз турында риваятькә тукталмаска иде? Аксак Тимер токымы, хан кызын танып, Сәмәркандка алып китү өчен генә яндыра лабаса. Әгәр дә хан кызы Нәргизә илбасарларны алдап Кара пулатка алып керсә һәм дошманны шунда яндырып үтерсә, либреттоның очы очына ялганыр иде әле. Бу очракта хан кызының каһарманлыгы нидән гыйбарәт соң? Өстәвенә, спектакльдәге тарихи вакыйгаларга мәхәббәт сызыгы килеп кушылган. Ике сюжет тагын бер-берсенә ятмый. Нәргизә һәм Турыбатырның мәхәббәте һәм ил сакчыларын данлау темалары һәркайсы үзенә аерым яши бирә сыман. Күпме җәзаласалар да, Турыбатыр хан кызын күрсәтми һәм шуның белән вәссәлам. Әгәр дә әсәрнең моннан берничә ел элек иҗат ителүен белмәсәң, автор либреттоны Украина канкоешы турындагы сводкалар тәэсирендә язган дигән фикергә килергә мөмкин. Матур лирик риваятькә нигезләнгән әсәрдә Турыбатырны шулкадәр җәзалауларын, хәтта сәхнә түрендә ботыннан асып куюларын башкача ничек аңлатырга? Артист өчен йөзтүбән асылган килеш партия җырлау үзе җәза.

Әмма никтер «Кара пулат»тан шуннан ары кимчелек эзлисе килми. Безнең хан - ханбикәләребез көн саен сәхнәләргә чыкмый ла. Бүген бер театрда - Казанны яклап сугышкан Кол Шәриф, иртәгә - ире үлгәннән соң ханлыкны үз кулларына батырларча кабул итеп алган Сөембикә, ары китеп - Казан ханлыгына нигез салган Олуг Мөхәммәд, Бөек Болгар дәүләтенең беренче данлы ханы Кубрат һ.б. турында опера, драма спектакльләре карау бәхетенә ия булсак, бер-берсен чагыштырып, тәмләп сурәтләр идек. Әлегә опера һәм балет театрындагы кебек Сөембикә-ханбикәбезне сәхнәдә мәсхәрәләмәгәннәренә шөкер итәргә кала.

«Кара пулат»ны мактыйсы гына килеп тора, чөнки безнең җырчы егет-кызларыбызга ханнар булып сәхнәгә чыгар өчен бер мөмкинлек бу һәм алар бу мәртәбәгә бик лаек. Илүсә Хуҗина Нәргизәнең энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгән күлмәгеннән нинди затлы күренә! Тормышта да туры сүзле, һәрнәрсәгә үз фикере булган акыллы яшь җырчыбыз Илгиз Мөхетдиновка да Турыбатыр роле бик килешеп тора. Дөньяда ике явыз булса, аның берсе «Кара пулат»тагы Карабатыр дип белер идек, чөнки Артур Исламов бу рольне күзләреннән очкыннар чәчеп, тамашачыны өркетеп шундый оста итеп башкарды! Денис Ханбаба да һичшиксез яугирләр роленә лаек. «Кара пулат» булмаса, хан кызының дуслары – Динә Венедиктова, Элина Сафина, Диана Мөхетдинова, Эльвира Калислямова, Әнисә Вәлиева, Полина Зиннәтованы кайчан ишеткән, күргән булыр идек әле? Музыка сәнгатебездә күпме зиннәтле асылташыбыз бар! Кадерен генә белмибез.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мондый спектакльләр сәламәт милләт үстерә

«Минем өчен бу кич ачышлар киче булды», – дип, «Созвездие-Йолдызлык» арт-резиденциясендә булганнан соң, хис-кичерешләре белән уртаклашты язучы Разил Вәлиев.

Сүз режиссер Рәшит Заһидуллинның «Ерак йолдыз яктысы» спектакле турында. Бу әсәр үзәгендә – татар әдәбияты классигы Хәсән Туфан образы, аның тормыш юлы, хатынына һәм үз халкына тугры булган мәхәббәт, язмыш сынаулары һәм өметләре. Шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты күзлегеннән спектакльдә репрессияләрдән зыян күргән барлык иҗатчыларның портреты чагылдырыла.

«Безнең буын Хәсән Туфан шигырьләрендә үскән. Аның язмышын һәм иҗатын бик яхшы белсәм дә, бүген ул миңа башка яктан ачылды. Моның өчен Рәшит Заһидуллинга һәм аның гаҗәеп режиссерлык талантына рәхмәт әйтергә кирәк», – ди Р.Вәлиев.

Ул шулай ук әлеге спектакль киң җәмәгатьчелек байлыгына әйләнсен иде, дип белдерде: «Спектакльне яшь буын күрергә тиеш. Без аны Хәсән Туфан, Һади Такташ, Муса Җәлил кебек шәхесләр үрнәгендә тәрбияләсәк, республикада сәламәт милләт үсәчәк».

Спектакльнең тагын бер мәртәбәле кунагы – Казан цирк мәктәбе директоры Илдар Игумнов. Ул тамашада уйланырга этәрә торган җитди темалар күтәрелүен билгеләп үтте. «Бу спектакль мине цифрлы технологияләр һәм урбанизация чорында күп нәрсәне югалтуыбыз турында уйланырга мәҗбүр итте. Барыннан да элек – ул Хәсән Туфан буыны кешеләренең аерылгысыз өлеше булган патриотизм рухы. Бу спектакль теләсә кайсы ситуациядә кеше булып калырга өйрәтә», - дип саный ул.

«Татарстан» ДТРК директоры Фирдүс Гыймалтдинов исә спектакльдә бер язмыш мисалында бөтен халык язмышы уңышлы күрсәтелүенә шаккатуын белдерде. «Сюжет, режиссер алымнары, декорацияләр, дөрес куелган ут, актерлар уены – болар барысы да онытылмас тәэсир калдыра торган бердәм пазлга җыела. Хәсән Туфанның поэзиясе уртак фикергә корылган, үземнең дә аның иҗаты белән якыннанрак танышу теләге уянды. Бу сюжетта бөтен ил язмышы шундый җиңел укыла, аңлашыла. Мөгаен, бу мине барыннан да күбрәк гаҗәпләндергәндер», – дип уртаклашты ул.

Кунакларның һәрберсе төп рольне башкаручы Искәндәр Нуриҗановның талантын аерым билгеләп үтте. Аларның сүзләренә караганда, Нуриҗанов күрсәткән искиткеч актерлык уены «Ерак йолдыз яктысы» спектакленең барлык өстенлекләрен берләштерүче буын булып тора.

Игезәкләр могҗизасы

35 яшьлек игезәкләр Лия Роджерс һәм Сара Мариуз АКШның төрле шәһәрләрендә яши. Алар бер-берсен еraktан да бик яхшы тоемлый. Икесе дә бер үк вакытта йөккә узарга планлаштырмаса да, очрашкач, аларның бер тирәдә бәби табасы ачыклана. Табигать исә игезәкләрнең эчке сәгатьләрен бик төгәл дөресли: Сара һәм Лия бер көндә, бер сәгатьтә генә түгел, бер үк минутта – икенче унсигез минутта бәби таба. Хатыннарның иманы камил: язмыш шулай хәл иткән икән, димәк, аларның балалары арасындагы бәйләнеш тә эниләренеке кебек үк нык булачак.

(“Лента.ру”).

Кайда тәмлерәк?

Мәктәп балаларына нинди ризык ашату турында бәхәсләр бер дә тынмый. Кемнәрдер, укучылар сыйфатлы әзерләнгән файдалы ризык белән генә тукланырга тиеш, дип саный, икенчеләре моны кыйбатсына һәм мәктәптә тамак ялгау өчен бераз арзанрак ашамлыклар да ярап тора, дип ышандырмакчы. Италиядәге стандарт сый җыелмасына руккола белән балык, томат соусы белән токмач, капрезе салаты, багет һәм йөзем керә. Финляндиядә укучыларга гадәттә борчаклы аш, чөгендер салаты, кишер, икмәк, җиләкле панкейк (коймак) бирелә. Франциядә бала-чага кыздырылган ит кисәге, кишер, кузаклы фасоль, сыр һәм җиләк-җимеш белән сыйлана. Көньяк Кореядә мәктәп балаларына гадәттә балык шулпасы, дөге белән тофу, кимчи һәм чи яшелчәләр бирелә. Греция мәктәпләрендә дөге белән томалап пешерелгән тавык, йөзем яфрагына төрелгән ит, помидор белән кыяр салаты, мандарин, анар белән йогырт яратып ашала.

(“Der Spiegel”).

Озак яшисең килсә, тиз йөре!

70 яшьтә җәһәт-җитез йөрүчеләрнең 80 яшькә җитү ихтималы 100 процент тәшкил итә. Япон галимнәре әйтүенчә, секундына 1,5 метрдан да ким булмаган тизлектә хәрәкәт итү җәһәт йөрүгә санала. Әгәр 70 яшьлек кеше шуннан акрынрак тизлек белән йөри икән, аның 80 гә җитү ихтималы 15-35 процентка гына тәңгәл. “Кеше гел җәһәт йөрергә күнеккән икән, ул һичшиксез озын гомерле булачак”, – ди Япония Гериатрия һәм геронтология милли үзәге президенты Хидэнори Арай. Белгечләр күзәтүе күрсәткәнчә, 1997 елдан бирле японнарның йөрү тизлеге уртача 5-10 процентка арткан. “60 яшьтән узучыларның физик халәте тотрыклы яхшыра бара: картлык һаман артка чигенә”, – ди Арай.

(“Batona.net”).

Урман үстергәннәр

Һиндстаннан Саалумарада Тимакка фермер ире Чикаях белән гомере буе кырда эшләгән. Аларның баласы булмаган, шунлыктан авылдашлары гел мыскыллаган. Көннәрдән бер көнне ир белән хатынның башына шәп фикер килгән: агачлар утыртып, аларны балаларны кайгыртkандай карап үстерергә булганнар. Авылга килә торган юл буена агач утырткannар, суны берничә чакрымнан чиләк белән ташып сипкәннәр. Саалумарада белән Чикаях утырткан агачларның саны тора-бара 384 кә җиткән, хәзер бу урман барлыгы 1,5 миллион рупиягә бәяләнә.

(“Вокруг света”).

Йөз еллык хата

1898 елда The New York Times газетасының беренче битендә җибәрелгән хатаны 100 ел буе беркем дә күрмәгән. Шул елның 6 гыйнварында газетаның 14499 нчы саны чыккан, ә 7 гыйнварда ни өчендер 15 меңенче сан пәйда булган. 1999 елда газетаның бер хезмәткәре, архивта казынганда, 500 санга ялгышуны күреп алган. Хатаны инде яңа меңьеллыкта төзәткәннәр – 2000 елның 1 гыйнварында The New York Times газетасының 51254 нче саны чыккан, аннан алдагысы исә 51753 нче сан булган.

(“ИнтересNIK”).

Чикләвек симерүдән саклый

Көн саен чикләвек ашау симерүдән һәм аңа бәйле чирләр килеп чыгудан саклый икән. АКШтагы Гарвард университеты галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. Тикшеренүдә сәламәтлек саклау тармагында эшләүче 40-75 яшьлек 51 529 ир-ат һәм 24-44 яшьлек 238 386 шәфкать туташы катнашкан. Аларны 20 ел буе күзәткәннәр. Катнашучылар узган елда барлыгы ничә порция чикләвек ашаганнарын (тәүлеклек бер порция – 28 грамм) һәм үз авырлыкларын дүрт елга бер тапкыр хәбәр итеп торган. Шулай ук атна буена ясалган күнегүләр, шул исәптән җәяү йөрү, йөгерү, велосипедта йөрү, йөзү дә исәпкә алынган. Теләсә нинди чикләвекне еш ашаган кешенең ябык булуы ачыкланган. Әйтик, дүрт ел буе көндәлек нормага тагын шуның яртысын өстәп сыйлану тән авырлыгын шул арада ике килограммга киметә ала. Шул ук микъдарда әстерхан чикләвеге ашау симерү куркынычын 15 процентка киметә. Чикләвекне чәйнәгәндә, күп энергия тотыла, андагы клетчатканың күплеге исә озак вакытка туклык хисе тудыра.

(“MedicalXpress”).

Картлар космоска очамы?

